АУЛАК БӘЙРӘМ

Бер кешелек авылларда Яңа елны ничек каршы алалар?

> 19

БАЛАЧАК ҖЫРЫ

Балалар репертуарына «Кайда сез, җырлар?» – дип ялварырга калып барабыз түгелме?

> 20

РӘНИФ ШӘРИПОВ:

«Бу дөньяның, бу тормышның ямьсез, гаделсез якларын күрсәм, шунда ук ачуым чыга»

> 22

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 189 (29155) | Җомга | 22 декабрь | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

«Татар-информ»

ТОРМЫШ ЮЛЫ

МӘСКӘҮ – КАЗАН ТРАССАСЫ АЧЫЛДЫ

Ил тарихында иң куәтле, иң тиз йөрешле һәм иң заманча юл. М12 автомобиль трассасы төзелеше турында бу. Мәскәү – Казан юлын кулланышка тапшыру тантанасында Россия Президенты Владимир Путин юлчыларга рәхмәт әйтте. Ә Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов аны беренчеләрдән булып сынап карады.

> 5

Ишетми калмагыз

Татарстан Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы, күпләрнең кызыксынуын исәпкә алып, киләсе елның гыйнварында бәйрәм көннәре турында аңлатып үтте. Россия Хезмәт кодексы нигезендә 1, 2, 3, 4, 5, 6 һәм 8 гыйнварда – Яңа ел каникулында һәм 7 гыйнвар – Раштуа көнендә ял итәчәкбез.

Ә инде еллардан, бәйрәм көннәреннән нәтиҗәле файдалану өчен, Хөкүмәт карары нигезендә 6 гыйнвар – шимбә ялы 10 майга (җомга), 7 гыйнвар – якшәмбе ялы 31 декабрьгә (сишәмбе) күчерелгән.

Шулай итеп, атнасына биш көн эшләүчеләр 2024 елда 1–8 гыйнварда ял итәчәк.

Кош-корт һәм йомырка җитештерүчеләр саны буенча Татарстан төбәкләр арасында беренче урынга чыккан. Бездә әлеге өлкәдә 306 предприятие һәм оешма эшли. «ТАСС» агентлыгы хәбәренә караганда, иң күп оешмалы төбәкләр арасында, Татарстаннан тыш, Краснодар крае (269 оешма), Башкортстан (245), Дагыстан (190) һәм Ростов өлкәсе (167) бар. Шул ук вакытта төбәкләрдә 2021 елдан бирле мондый оешмалар саны кимегән.

Быел республикада күпфатирлы йортларны капиталь төзекләндерүгә 6 миллиард сум чамасы акча бирелгән. Татарстан Дәүләт торак инспекциясе җитәкчесе Сергей Крайнов әйтүенчә, шуның 1 миллиарды – республика бюджетыннан, тагын 1 миллиарды – муниципаль берәмлекләр бюджетыннан һәм 4 миллиарды – капиталь төзекләндерү фондыннан. 2008–2023 елларда күпфатирлы йортларны ремонтлауга барлыгы 90 миллиард сумнан артыграк тотылган.

Сүз уңаеннан, киләсе ел башыннан капиталь төзекләндерү өчен түләү күләме артып, бер квадрат метрга 7,7 сум тәшкил итәчәк. Быел бу сумма – 6,95 сум.

Киләсе атна башында Татарстанда –8 градуска кадәр суыта. Бу елларда исә болытлы, бик җылы һәм дымлы һава сакланып кала.

Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, шимбә – 23 декабрьдә кар көтелә. Һава температурасы –3…+1 градус чикләрендә тирбәләчәк. Якшәмбе – 24 декабрьдә көндез термометрның терекөмеш баганасы +1…–2 градус күрсәтәчәк. Төнге сәгатьләрдә –1…–6 градуска кадәр төшә.

Синоптикларның башлангыч мәгълүматлары буенча, дүшәмбе – 25 декабрьдә Татарстанга салкын һава агымы үтеп керәчәк. Кар явачак. Көндез 0…–5, төнлә –2…–7 градус булачак. Сишәмбе – 26 декабрьдә аз гына кар. Һава температурасы –3…–8 градуска кадәр түбәнәячәк.

Районнарда ни хәлләр?

Баулы

Район башкарма комитетының ЗАГС бүлегендә өч игезәкнең әти-әнисенә бала туу турында таныклыклар тапшырдылар. Рузанна һәм Артур Торосяннар гаиләсе хәзер 5 бала тәрбияли. 6 яшьлек Ангелина белән 12 яшьлек Марианна янына тагын ике малай һәм бер кыз – Григор, Геворг һәм Марияне алып кайттылар. ЗАГС бүлеге хезмәткәрләре, күпбалалы әти-әнине сабыйлары туу белән тәбрик итеп, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов исеменнән котлау тапшырды. Районда соңгы ун елда өч гаиләдә өчәр игезәк бала дөньяга килгән. Быелтыр Алинә һәм Радик Таҗетдиновлар гаиләсендә өч кыз туган иде.
(«Баулы-информ»)

Яшел Үзән

Большие Ключи авылында яшәүче Мәрдановлар яңа йортка күченде. Июнь аенда янгын чыгып, җиде балалы гаилә йортсыз-түбәсез калган иде. Аларга район хакимияте, битараф булмаган кешеләр ярдәмгә килә. Изге эшкә «Меценатлар» җәмгыятеннән эшмәкәр-хәйриячеләр дә кушыла. Алар төзелештә ярдәм итә, материаллар ала. Нәтиҗәдә тиз арада 100 кв. метр мәйданлы бер катлы яңа йорт барлыкка килгән. «Кыска вакыт эчендә без бергәләп бу йортны төзи алдык. Берләшеп, ярдәм итә алдык. Бу – безнең уртак эшебез. Мондый мизгелләрдә җирдә юкка гына яшәмәвеңне аңлыйсың. Мондый мисаллар белән безнең җәмгыять үсәчәк, бердәм һәм көчле булачак», – ди эшмәкәрләр берләшмәсе рәисе Ильяс Гыймадов.
(«Татар-информ»)

Мамадыш

Югары Ушма авыл советы һәм җирле мәдәният йорты хезмәткәрләре Бәрия Газизованы 100 яшьлек юбилее белән котлады. Йөзьяшәр әбигә Россия Президенты һәм Татарстан Рәисенең котлауларын, район башлыгы Анатолий Ивановның бүләкләрен тапшырдылар. Хәзерге вакытта Бәрия әби кызының гаиләсендә Чаллыда яши. Аның 8 оныгы, оныкларының 13 баласы бар.
(«Нократ»)

Чаллы

Шәһәр дельфинариенда кечкенә дельфин баласы туган. Ул – илебезнең Кызыл китабына кергән Кара диңгез афалинасы нәселеннән. Аны 32 яшьлек Зоя кушаматлы дельфин дөньяга китергән. Бу – аның икенче сабые. Дельфиннарның табигый булмаган шартларда үрчүе – бик сирәк күренеш, шуңа күрә Чаллы дельфинарие хезмәткәрләре үзләрендә мондый могҗизаның инде бишенче тапкыр кабатлануы белән бик горурлана. Хәзерге вакытта дельфин баласы тәүлек әйләнәсе күзәтү астында.
(«Шәһри Чаллы»)

БУРЫЧЛАР КУЕЛГАН

«Татар-информ»

Киләсе ел республикада Фәнни-технологик үсеш елы дип игълан ителде. Татарстан Фәннәр академиясенең яңа Президенты Рифкать Миңнеханов ел нәтиҗәләренә йомгак ясап, киләсе елга бурычларны билгеләде. Быелгы ел нәрсәсе белән истә калачак?

Утырыш быел мәрхүм булган галимнәрне искә алудан башланды. Алар – филология фәннәре докторы Мирфатыйх Зәкиев, техник фәннәр докторы Ирек Фәхретдинов һәм Татарстан Фәннәр академиясенең мактаулы әгъзасы, халык шагыйре Разил Вәлиев.

Рәис Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сәфәров 2023 елны соңгы ун елда университет, фән оешмалары өчен иң уңышлысы дип бәяләде. Монда ул узган атнада тагын бер вуз – Казан илкүләм тикшеренүләр технологик университетының «Приоритет-2030» программасының махсус өлешенә керүен, ә Казан медицина университетының әлеге программаның төп өлешендә катнашуын әйтеп узды. Шулай ук Казан илкүләм техник университет һәм Әлмәт дәүләт нефть институтының алдынгы инженерлык мәктәпләре арасыннан сайлап алынуын зур казаныш дип атады. Кыскасы, республикада югары дәрәҗәдәге биш фәнни-мәгариф мәйданчыгы эшләячәк. Мисал өчен, Мәскәүдә бу күрсәткеч – 11, Санкт-Петербургта – 6.

– Республика – «Студентлар стартабы» бәйгеләрендә җиңүчеләр саны буенча ил төбәкләре арасында беренче урында. Яшьләрне фәнни эшкуарлык белән таныштыру студентлар тәҗрибәсе генә булып калырга тиеш түгел. Әлеге проектларны тормышка ашыруда ярдәм итәргә, алардан яңа буын технологик эшмәкәрләр чыксын өчен тырышырга кирәк, – диде Әсгать Сәфәров.

Аның әйтүенчә, уртак тырышлык фәнни-мәгариф өлкәсенең төп эшчәнлегендә чагылыш тапкан. Әйтик, соңгы 15 елда беренче тапкыр республикада фәнни эшләнмә һәм тикшеренүләрдә катнашучылар саны 14 меңнән арткан. Фәнгә киткән эчке чыгымнар күләме 25 процентка, ягъни 28 миллиард сумга җитә. Күптән түгел игълан ителгән фәнни һәм технологик казанышлар рейтингында Татарстан Мәскәүдән генә калыша. Ирешелгән уңышлар Фәнни-технологик үсеш елын үткәрүгә нигез булачак.

Рифкать Миңнеханов исә киләсе елда университет, технопарк, предприятиеләр белән берлектә яңа фәнни экосистема булдырылачагын әйтте. Шулай ук уйлап табу эшенә дә аерым игътибар бирмәкчеләр.

– Киләсе елга беренче тапкыр яшьләр өчен күргәзмә, белем бирү программалары, профильле креатив киңлекләр булдыру чараларын финанслауга акча таба алдык, – диде Рифкать Миңнеханов. Моннан тыш, 2024–2026 елларда фәнни-технологик үсеш программасы өчен өстәмә 723 миллион сум акча бүлеп бирелгән.

Җыелыш ахырында Рифкать Миңнеханов Фәнни-технологик үсеш елының ике төрле логотибы белән таныштырды. Берсендә – канатлы барс, икенчесендә татар халкының милли бизәге лалә сурәтләнгән. Залда утыручы галимнәр дә үз фикерләрен әйтте. Бу логотиплар республика Хөкүмәтенә тәкъдим ителәчәк. Соңыннан фәндә уңышка ирешкән галимнәрне тәбрикләделәр. Физика-математика фәннәре докторы Мәкъзүм Сәлахов «Фәндәге казанышлар өчен» Татарстан Фәннәр академиясенең алтын медале белән бүләкләнде.

Сәрия МИФТАХОВА

ТЕРЕМЕ СИН, МИЛЛӘТ?

Журналистларның Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев белән очрашуы әнә шул сораудан башланып китте дә Йолдыз авылы, Сабан туе, халык саны алу һәм башка темаларга кадәр барып җитте.

ЙОЛДЫЗ АВЫЛЫ

Быел Курган өлкәсендәге Йолдыз (Эчкен) авылында булган вакыйга, мөгаен, һәр татарның йөрәгендә яра булып торадыр. Билгеле, хәзер анда төзекләндерү эшләре, авылны торгызу бара. Васил Шәйхразыев та янгын чыккан авылга тәүге сәфәрен искә төшерде.

– Май ае иде. Авылны күргәч тә, күз алдыма сугыш килде. Авылга фашистлар килеп, бөтен нәрсәне яндырып киткәннәр төсле… Ә кешеләр… Аларның ул чакта күзләрендә яшь тә юк иде. Башларына төшкән фаҗигагенең зурлыгына да төшенмиләр, алар өчен тормыш мәгънәсе юкка чыккан, чөнки бер сәгать эчендә бөтен нәрсәләре, моңарчы тапкан мал-мөлкәтләре янган да беткән, – диде ул. – Иң беренче эш авыл халкына өмет бирү, аларны эчке төшенкелектән коткару иде.

ҖАНИСӘП

Мәгълүм булганча, 2021 елда узган халык санын алуда 600 меңләп татар кешесен югалттык. Васил Шәйхразыев, моңа төрле сәбәпләр киртә булды, дип кабатласа да (әйтик, коронавирус зәхмәте), җаваплылыктан баш тартмады.

– 2030 елдагы җанисәп сыйфатлы үтәргә тиеш. 2010 елда булган 5,3 млн татарны шулай кире кайтара алачакбыз. 7 елдан соң булачак җанисәп уңышлы узсын өчен, хәзердән үк эшләр башкарыла, – диде ул.

МИЛЛӘТ

«Безнең милләт үлгәнме, әллә йоклаган гынамы?» – дип сорадылар Васил Шәйхразыевтан.

– Безнең милләт тере. Җитәкче булгач, милләттәшләребез белән күп аралашырга туры килә. 2023 елда мин 56 төбәктә, 6 илдә булдым. Җәмгысы 145 көн командировкада идем. Һәрберсенең нигезендә – милләттәшләр белән очрашу. Кайдадыр 10–15 кеше, кайдадыр мең кеше, Сабантуйларда 50 меңләп һәм аннан да күбрәк кеше җыела. Безнең милләт тере дип әйтә алам, – диде ул.

vk.com

ТӨРЛЕ-ТӨРЛЕ УТЛАР ЯНА...

Бәйрәм кәефе

Иң тылсымлы бәйрәмгә һәм иң озын ялларга кадәр күп калмады. Татарстанның Хөкүмәт йортында да республика халкы бәйрәмне дә, ялларны да шәп итеп уздырсын дип телиләр. Шуңа бу атнада, журналистларны җыеп, Татарстанда узачак чаралар турында сөйләделәр.

Балаларга – Кыш бабай белән Кар кызы

Татарстанның Яшьләр эшләре министрлыгы кышкы каникулга ниләр әзерли? Министр Ринат Садыйков сөйләвенчә, декабрь азагында һәм кышкы каникул чорында 89 сәламәтләндерү оешмасында 7394 баланы бушлай ял иттерергә җыеналар. Моннан тыш, каникулда төрле юнәлештәге 57 смена узачак. «Балалар өчен Яңа ел мохите ясарга тырышачакбыз. Һәр лагерьга Кыш бабай белән Кар кызы киләчәк», – дип вәгъдә бирде министр Ринат Садыйков.

Район һәм шәһәрләрдәге яшьләр үзәкләренең, үсмерләр клубларының да ялларда ишекләре ачык булачак. Алар шулай ук Яңа елга багышланган махсус программа әзерли.

Туризм комитеты киңәшләре

Татарстанның Туризм буенча дәүләт комитеты ялларда өйдә ятмаска киңәш итте. Комитет рәисе Сергей Иванов берничә яңа һәм бик үк яңа булмаган ял итү ысулы турында сөйләде. Әйтик:

- Лаештагы «киноавыл» – Семрукка барып, аннан кайтышлый яңарак кына ачылган Державин музеена кереп чыгу (икесе дә 2 гыйнвардан эшли);
- Тәтешкә сәфәр кылу;
- Яңа елга яңача бизәлгән Иске Татар бистәсен һәм Алабуга шәһәрен күреп кайту;
- Таудан чаңгы шуу комплексында ял итү (алар Югары Ослан, Кукмара, Әлмәттә һәм Чаллы шәһәре янында бар. Тиздән Мамадышта ачылачак);
- Балалар белән бергә Арча районының Яңа Кырлай авылындагы Кыш бабай һәм Кар кызы резиденциясенә бару.

Мәдәниятле ял

Мәдәни чаралар турында Татарстанның мәдәният министры урынбасары Юлия Әдһәмова сөйләде. «Ялларга программа әзерләгән вакытта, мәдәният учаклары гаилә белән вакыт уздыруны күз уңында тотты», – диде ул. Мәдәни чараларга һәр район үзенчә әзерләнә.

Бәйрәм күңелсез тәмамланмасын өчен, куркынычсызлык кагыйдәләре турында онытмыйк. Татарстанда бу елның 25 декабреннән 2024 елның 8 гыйнварына кадәр янгынга каршы махсус режим гамәлдә булачак. Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан буенча Баш идарәсе җитәкчесе урынбасары Максим Трущин кайбер кагыйдәләрне искә төшерде.

– Пиротехниканы махсус кибетләрдән сатып алырга кирәк. Кулланыр алдыннан аның инструкциясен һәм саклау таләпләрен укып чыгу зарур. Пиротехниканы җылыткыч һәм электр җиһазларыннан читтә сакларга, балалардан яшереп куярга кирәк. Фейерверк һәм салютларны кулланыр алдыннан, өстә электр чыбыклары һәм агачлар булмавын тикшерегез. Әгәр дә пиротехника кабынмаса, аның янына 10 минуттан соң гына килергә ярый, ә чүп савытына 24 сәгать буе суда тотканнан соң ташларга кирәк, – дип сөйләде белгеч.

Брифингта телгә алынганнарның иң кызыклыларын санап үтик. Әйтик, Казандагы Горький һәм Шаляпин музеенда пешекче бик борынгы рецепт буенча күмәч пешерергә өйрәтәчәк. Алабуганың Дәүләт музей-тыюлыгында узачак интерактив программаларда катнашучыларга сугыш вакытында Яңа елны ничек уздырулары турында сөйләячәкләр. Ә «Зөя утрау-шәһәрчеге» музей-тыюлыгы балалар һәм әти-әниләр өчен пыяладан чыршы уенчыклары «кабарту» буенча остаханәләр әзерли. Болгардагы тарихи-архитектура музеенда 22 декабрьдән «Яңа ел открыткасы тарихы» дип исемләнгән күргәзмә эшли башлаячак. Кыскасы, ялларын үзенчәлекле итеп уздырырга теләүчеләр өчен сайлау мөмкинлеге шактый зур. Хәтта әнә яңа һөнәрләр үзләштерергә дә була.

Аждаһалы башкала

Аждаһаны куып тоткан кешегә – бүләк, чанасы булганнарга – тау һәм көн саен бәйрәм. Казан мэриясенең мәдәният идарәсе башлыгы Азат Абзалов башкалада узачак очсыз-кырыйсыз чаралар турында сөйләде. Аждаһадан башлыйк. 2–5 гыйнвар көннәрендә Казан буенча ел символы йөреп торачак. Аны куып тоткан кешегә – бүләк! «Очып йөрерме ул, атлапмы – монысы сер», – диде Абзалов, уенын-чынын кушып.

Елдагыча, Яңа ел төнен «Казан» гаилә үзәге янындагы мәйданда һәм «Черек күл» паркында уздырып булачак. Бәйрәм 1 гыйнвар көнне 2.00 сәгатькә кадәр гөрләячәк. Һәм 1 гыйнвар киченнән алып 8енә кадәр көн саен шәһәрнең барлык паркларында да дәвам итәчәк.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Язучы фикере

Чишмә

Тирә-якны кар каплаган инде. Бөтен дөнья кышны ябынып йоклый. Ә ул талгын гына челтерәп ята. Чишмә челтерәвен җәйләрдә бик ишетеп тә булмый, ә кыш көне – аның тавышы гына. Һәм ул безгә нидер сөйли кебек. Миңа гына шулай тоеламы...

– Бөек иҗатчыларыгыз илһам килгәнен көтә бит әле, шуннан кеше күңеленә кереп, чорлар буе балкырлык әсәрләр тудыралар. Ә мин үзем илһам шикеллемен. Җирнең күкрәгеннән бер кодрәт белән ургылып чыгам да сезгә ашыгам. Шаян дулкыннарым көндезләрен кояш нурлары белән шаярыша, төннәрен ай-йолдызлар белән уйный. Тукталып уйланып торган урыннарда мин галәмне чагылдыручы тере көзгегә әвереләм. Сикереп кенә чыгарлык киңлектә, тез тиңентен генә тирәнлектә булсам да, кайдандыр башланып кайдадыр тәмамлансам да, миндә чиксезлек чагыла. Чиксезлекне сыйдыра алганнар кечкенә була алмыйдыр. Зур булу өчен күләм мотлак түгел.

Үз юлымны мин үзем ярып барам. Кайчагында туры гына барам, кайчагында урау юллар, кискен каршылыклар аша узам. Кайчагында дәртле җырлар сузам, кайвакытта талгын моңга күчәм. Тын тоелган чакларым да була. Тик мин хәрәкәттә. Тына алмыйм. Теләмим дә, алай ярамый да. Чишмә – хәрәкәттә чакта гына чишмә, туктап калса, сазга әверелә.

Бу заманда чишмә булу... Чишмә булуның кыенлыгы бик юк инде аның. Бәям генә түбән. Матди яктан гына авыррак. Искә алганыгыз бардыр инде: лимонадларны, куас, сыра кебек нәрсәләрне кешеләр фәләнешәр сумга сатып ала. Өйгә үткәрелгән су өчен дә хаклар айдан-айга артып тора. Ә чишмәләр нинди генә саф, гүзәл һәм татлы булсалар да, кадерләре артмый. Чишмәгә тиеннәр генә ташлыйлар. Чишмәләрдә булганыгыз, аларның төбендә ялтырап яткан көмеш тәңкәләрне сезнең дә күргәнегез бардыр инде? Минем матди хәлем дә шул чишмә шикеллерәк. Беләм инде, лимонад булсам, күбрәк түләрләр иде. Тик аның өчен бераз гына булса да ясалмалык кирәк. Ә мин үземнән нәрсәдер ясаганнарын яратмыйм, мин үзем ясарга яратам. Үз юлымны үзем ярып барам. Чишмә ул – иҗатчы. Иҗат – үзеңә кирәк нәрсәләрне үзең ясау.

«Чишмәгә бу тиеннәр ни пычагыма кирәк?» – дип уйлап куйганыгыз да бардыр әле. Тиеннәр кирәкми чишмәгә. Сумнар да кирәк түгел. Хәтта потлап алтын ташласагыз да, чишмә барыбер үзе булып кала. Ул үзгәрми. Чишмә үзенчә яши.

Чишмәләр бай да, ярлы да була алмый. Сез ул байлар, сез ул хәерчеләр. Ә мин – чишмә. Ә сез мине теләсә кайсы вакытта эчеп китәргә мөмкинсез. Сусыннарыгыз басылганчы, эчләрегез күбенгәнче. Рәхмәт укырга мөмкинсез. Үзегезгә рәхмәт! Рәхмәт хисе – күчеп йөри торган нәрсә. Эстафета кебек. Рәхмәтемне әйбәт кешеләргә тапшырыгыз, рәхмәт хисе – тик әйбәтләр өчен.

Эчеп туйгач, төкереп тә, печ итеп тә китәргә мөмкинсез. Сез – ирекле илнең гражданнары, сезнең моңа хокукыгыз тулы. Тик мин сезнең нәҗесләрдән газапланмыйм. Агымнан түбәндәрәк торучылар бар... Алар да сезнең начарлыкны тоймаячак... Гади, надан һәм эшкинмәс булганнары өчен түгел... Минем сафлык күп нәрсәне эретә. Яктылыкта – караңгылык, изгелектә – явызлык, мәхәббәттә нәфрәт эри. Яратырга кирәк. Ихластан. Яратып кылган хата ялгышып яратудан яктырак. Кайчагында. Бу дөньяда бар да буталган ул... Җаныгыз ни куша – шуны эшләгез. Тик чаманы белегез. Явызлыкта арттырып җибәрмәгез. Үкендерми торган явызлык юк. Үкендерми торган гөнаһ та юк.

Чишмә ага... Без дә билгесезлек куеныннан ургылып чыккан чишмәләр шикелле кайдадыр агабыз, нидер кыланабыз, нәрсәдер сөйлибез... Без дә үз юлыбызны үзебез ярырга, үзебезчә яшәргә дип тынгысызланабыз.

Чишмә ага. Без яшибез... И-и-и...

Без дә яшибез инде...

Марат КӘБИРОВ

Әйтеп кенә бактым

Онытылу

Риман
ГЫЙЛЕМХАНОВ

Разил Вәлиевнең кырыгы узгач, икенче көнне үк аның каберенә бардык. Кабер янына тездән кар ерып кердек без. «Без» дигәнем – Разилнең авылдашы, дусты, фикердәше Алмаз Хәмзин, Татарстанның халык шагыйре Зиннур Мансуров һәм мин. Кабер тирәсендә аяк эзләре юк иде, димәк, килүче булмаган. Югыйсә бер көн алдан гына аны искә алу мәҗлесендә йөздән артык кеше утырган иде. Дин әһелләре әйтүенчә, вафатына 40 көн тулганда, мәрхүмнәрнең каберенә килеп дога уку мәҗбүри түгел, әмма укысаң яхшы.

Белгәннәребезне укыдык, Разил дустыбыз турында истәлекләр уртаклаштык. Хәер, сүзем бу турыда түгел, Разилнеке белән янәшә Фәндәс ага Сафиуллин кабере. Аның үлгәненә инде өченче ел китте, тик кабер өстендә җирләгәндә кадап калдырган тактадан башка берни дә юк. Инде кабере дә иңгән. Күрәсең, Фәндәс ага онытыла бара. Тукайның кеше кадере турында әйткәннәре күңелгә килә. Зиннур аның сүзен сүзгә яттан белә икән. «Минемчә, онытылу, тибәрелү үлемнән яманрак. Үзем үлсәм дә, гаҗиз исмем үлмәсен, югалмасын; минем тырышлыгым һәм эшләрем бушка китмәсен! Бармыни бездә, гомумән, чын кеше кадрен белү?! Без аны кайдан белик, мискин үлеп аңлатмагач?!» Бөек шагыйребезнең моннан бер гасырдан артык элек әйткәннәре бу! Күрәсең, кеше кадерен белү – гомерлек мәсьәлә.

Бүген берәүне дә гаеплисе килми. Әмма безнең халыкта «Үлгәннәрнең каберен бел!» дигән сүзләр бар. Аны Шәүкәт Галиев шигырь калыбына салып: «Исәннәрнең кадерен бел, үлгәннәрнең каберен бел!» – дип язып калдырган. Мондый сүзләр татар авылларының зират коймаларына да язылган һәм исәннәрнең вазыйфаларын искә төшереп тора.

Сүз дә юк, мәрхүмнең каберен карап тоту – иң әүвәл аның туганнары бурычы. Мин беткән авылларның зиратларын карап тоту очракларын да, шул зиратка мәрхүмнәрнең туганнары кайтып йөрүен дә беләм. 2010 елны Кытайга баргач, андагы кардәшләр безне зиратка алып барды. Ул зиратның татарлар күмелгән өлешен, шуңа тагын күпмедер җир өстәп, Кытай хакимиятеннән алтынга сатып алганнар. Дөньяның төрле кыйтгаларына таралган татарның инде менә ничә буыны бабалары рухына дога кылырга ел саен шул зиратка кайтып йөриләр икән. Кытай кайда да без кайда, диярсез. Шуңа күрә үзебезгә кайтыйк әле.

Күңелне бер уй борчый: мәрхүмнәр арасында танылган шәхесләр, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре дә бар бит әле. Димәк, аларга дәүләт кайгыртуы да тиештер. Шул ук Фәндәс ага – татар язмышы өчен җан атып яшәгән шәхесләребезнең берсе. Татарстан Югары Советы, Татарстан Дәүләт Советы депутаты буларак, республикабызның дәүләт суверенлыгы турында Декларацияне, Татарстан Конституциясен, «Татарстан халыклары телләре турында» Законны эшләүдә турыдан-туры катнашкан шәхес иде ул. Россия Думасында депутат булганда да Татарстан мәнфәгатен яклады. Һәр чыгышы дәлилле иде, кайбер сәясәтчеләрне, җитәкчеләрне авыр хәлгә дә куя иде Фәндәс ага. Шуңа күрә кайбер даирәләр өчен «уңайсыз» кеше дә булды.

Ике шәхесебезнең кабере янәшә, дидем. Алар милли азатлык хәрәкәтендә дә 30 ел бергә булдылар. Үзенә 85 яшь тулгач, бер очрашуда Фәндәс ага Разилгә: «Мин үзем турында уйламыйм, милләт, тел, татар мәктәпләре язмышы өчен борчылам. Мин китәрмен, милләт калыр, аны ни көтә, безне алыштырырдай яшьләр табылырмы?» – дигән булган.

Яшьләр табылыр үзе, тик менә аларны Разилләр, Фәндәсләр, Туфаннар рухында тәрбияләү кирәк. Димәк, ил, республика, милләт язмышын үзенеке кебек кабул итеп яшәгән олпат шәхесләребез онытылмаска тиеш.

КЫТАЙ АУГАНДА, БЕЗ НИШЛӘРБЕЗ?

Рәшит
ФӘТХРАХМАНОВ

САКАЛЛЫ ФӘЛСӘФӘ

Глобаль икътисадның дәһшәтле кризисы бу юлы Көнчыгыштан – Кытай тарафыннан килә. Әйе, Европада да хәлләр шәп түгел, Америка да финанс тотрыклылыгы белән мактана алмый, фәкыйрь саналган илләрнең күпчелеге ярымдефолт хәлендә. Рәсми статистика Кытай икътисадының үсешен күрсәтә, бары тик үсеш темпларының кимүе турында гына сүз алып бара.

Әйтик, өченче кварталда Кытай эчке тулай продуктының үсеше 4,9 процентка кадәр кимеде. Беренче яртыеллыкта үсеш 5,5 процент булган. Теләсә кайсы Көнбатыш иле мондый темпларга ирешсә, тантанага сәбәп булыр иде. Владимир Путинның күптән түгел ясаган чыгышын искә төшерик әле. «Россиянең үсеш темпы 3,5 процентка җитәргә мөмкин» дигән сүзләрне ул уңыш билгесе буларак әйткән иде. Ни өчен Кытайның 4,9 процентлык үсеше начар да, безнең 3 процентлык адым да алгарыш буларак кабул ителә? Шул сорауның җавабын табарга тырышып карыйк.

Бердән, барлык илләрдә дә статистика – миләрне юдыру коралы ул. Кытайда аеруча. Бүген аларда икътисадтагы начар тенденцияләр турында сөйләү тыелган. Атаклы икътисадчылар да, мәсәлән, дефляция турында авыз ачып бер сүз дә әйтә алмый. Социаль челтәрләрдә проблемалар турында сүз кузгату куркыныч. Бик хәвеф дигәндә социаль рейтингның түбәнәячәк. Рейтинг түбәнәю Кытайда хокукларың кысылуга китерә: чит илгә чыга алмыйсың, рестораннар-кунакханәләргә юл бикләнә, медицина ярдәме дә чикләнергә мөмкин. Кара исемлеккә кертелгән кешеләргә телефоннан шалтырату да хәтәр хәтта. Шалтыратсаң, телефоныңда махсус көй уйный башлый, «Бу кешедән ераграк тор», – ди. Хөкүмәтнең икътисадый сәясәтеннән риза булмаган зур гына бизнесменнарның бөтенләйгә юкка чыгу мисаллары җитәрлек. Шундый шартларда рәсми статистика саннарына ышана алабызмы?

Аннан соң статистика ничек исәпләүгә дә бәйле ул. Эчке тулай продукт бар илләрдә дә акчалата исәпләнә. Башка берәмлеге була да алмый инде аның. Россия икътисады, мәсәлән, сумнарда исәпләгәндә 2,5–3 процентлы темплар белән үсеп бара. Хисапны долларларга күчерсәк, эчке тулай продукт, 2022 елгы белән чагыштырганда, 17 процентка кимегән. Шуңа күрә Кытайның рәсми үсеш саннары бик аз нәрсә сөйли. Саннар дөрес булган очракта да кытайларның чүпрә кебек кабарган бурычларын түләү өчен үсеш темплары җитәрлек түгел. Аннан Кытай тулай продуктының бер сәер ягы бар: ул җитештерелә, ләкин кулланылмый. Хәзер алар төзегән торак мәйданнарын квадрат метрлар белән түгел, квадрат километрлар белән үлчиләр. Дөрес булса, 3 миллиард кешегә җитәрлек торак төзелгән, әмма хәтта Кытайда да аның кадәр халык юк. Сатылмаган фатирлар ил икътисадын муенга бәйләнгән таш кебек упкынга сөйри. Торак бәяләре ил тарихында беренче тапкыр 19 ай рәттән түбәнәя. Кытай эчке тулай продуктының 30 проценты – торак йортлар. Тармакның җимерелүе нинди нәтиҗәләр бирәчәген шуннан күз алдына китерегез. Компартия, җимерелүне туктату өчен, барысын да эшләргә тырыша. Бюджеттан тармакка зур суммада акчалар бүленә. Дәүләт хисабына беркемгә дә кирәкмәгән фатирлар төзү статистиканы яхшырта ала, ләкин финанс хәлен начарайта.

Бер торак төзелешендә генә түгел, Кытай икътисадының башка тармакларында да шуңа охшаш хәл күзәтелә. Артык җитештерү кризисы аркасында Кытай корычына, автомобильләренә, көнкүреш техникасына экспорт бәяләре төшә. Илнең экспортка озатылган корычына бәяләр, мәсәлән, 40 процентка түбәнәйгән, автомобильләргә – 10 процентка. Нәтиҗәдә чит илләргә автомобиль сату ноябрь аенда 28 процентка арткан. Беренче карашка шәп бит инде, әйеме?! Әмма тышкы базарларга товар бәясен төшереп сату икътисадчылар телендә нәрсә дип атала әле? Демпинг дип. Демпингны бер илдә дә яратмыйлар, чөнки эчке базардагы бәяләрне төшереп, үз җитештерүчеләреңне авыр хәлгә куя. Кытай товарларын демпинг белән сату дөнья икътисадының астын өскә китерәчәк, чөнки корычның яртысын алар җитештерә, глобаль автомобиль җитештерүнең 30 проценты – шуларныкы. Евросоюз Кытай автомобильләренә бәяләр төшү уңаеннан махсус тикшерү үткәрә башлады инде. Һиндстан һәм Вьетнам Кытай адресына гаепләүләр яудыра. Демпингка каршы чаралар озак көттермәс, дип уйларга кирәк.

Икътисадның мәтәлчек атуын туктату, һич югында кичектерү максатыннан, компартия эре компанияләрне үз контроле астына ала. Дәүләт компанияләре исә компетентсызлык һәм зыянга эшләүнең югары үрнәген күрсәтәләр. 2016 елда аларның 42 проценты зыянга эшләгән. 2019 елда керемнәре эчке тулай продуктның 35 процентын тәшкил итүгә карамастан, дәүләт компанияләренең чиста табышы аның 3 процентын гына тәшкил иткән.

Югарыда сөйләнгән хәлләр СССРны искә төшерә. Совет державасының эчке тулай продукты начар түгел иде бит. Хәрби техникадан тыш әйберләр дә байтак җитештерелә иде. 1980 нче еллар ахырында бу юлларның авторы Арчада өр-яңа комбайннар кабер-леге яныннан үтеп йөри иде. Конвейердан гына чыккан урып-җыю техникасы беркемгә дә кирәкми. Арзан да әле ул җитмәсә.

«Ни өчен Кытай турында язасың?» – дип сорар, бәлки, укучы. Аның икътисады белән кендекләр бәйлеккәнгә. Бердән, Россия чималы нигездә шуларга сатыла. Икенчедән, безнең базардагы технологик продукция – асылда шуларныкы. Безнең автомобиль дип сатылган машиналарның да кайбакыт шилдыгы гына безнеке. Монополист буларак, чиннар безгә сатылган товарларга бәя төшерми, киресенчә, күтәрә, дип әйтәләр. Болардан да мөһимрәге: безнең финанс системасында юань хакимлек итә. Резервларда – шул, хәтта гражданнар да банк хисапларындагы акчаларын кытай кәгазьләрендә саклауны арттыра. Бу ил икътисады егылса (анысы исә котылгысыз, вакыты гына җитмәгән), Россия финанс системасы зур тетрәнү кичерәчәк, туплаган байлыклар бик тиз саегачак. Исән булсак, ул көнне күрербез, дип уйлыйм әле мин. Икътисадый хәлебез бик мактанырлык түгел. Азәрбайҗаннан 612 мең тавык йомыркасы китертү турындагы хәбәрләрне матбугат кыры зур вакыйга буларак хәбәр итте. Бу – Казан халкының яртысына бер кабарлык ризык.

ТОРМЫШ ЮЛЫ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Тарихи вакыйга

М12 «Көнчыгыш» автомобиль юлының Мәскәүдән Казанга кадәр өлеше кулланышка тапшырылды. Юл салучыларны әлеге вакыйга белән видеоэлемтә аша Россия Президенты Владимир Путин котлады. Тантаналы чарада Россия Премьер-министры урынбасары Марат Хөснуллин, Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов, илнең автомобиль юлы уза торган төбәк башлыклары, Мәскәү мэры Сергей Собянин, Россия транспорт министры Виталий Савельев һәм башка рәсми затлар (кайберләре видеоэлемтә буенча) катнашты.

Илбашы әйтүенчә, яңа юлдан Мәскәүдән Казанга кадәр араны (ә ул 800 чакрым чамасы) 6,5 сәгатьтә узарга мөмкин булачак.

– Бу – икеләтә тизрәк һәм куркынычсызрак дигән сүз. М12 аша гомуми йөк ташу күрсәткече артачак, ул эчке туризмны үстерү өчен дә яхшы этәргеч булып тора. Автомобиль трассасы төбәкләрнең инвестицион мөмкинлекләрен арттырачак. Һәрвакыт шулай бит ул, юл төзелгәч, анда тормыш кайный башлый, – диде Президент.

Владимир Путин әлеге әһәмиятле юлны төзүдә катнашучыларга рәхмәт тә әйтте.

– Гаять зур хезмәтегез, эшне бик кызу тотуыгыз һәм төзелешне графиктан алда төгәлләвегез өчен рәхмәт! Кыска гына вакыт эчендә – өч елда шундый зур һәм катлаулы проектның бездә беркайчан да тормышка ашырылганы юк иде әле, – диде ул. – Юл төзелеше проектын тормышка ашыру – Россия белгечләренең сыйфатлырак, тизрәк һәм күбрәк төзи алуына тагын бер дәлил.

Юл салуның ние бар дигәндәй, бу эшнең бик катлаулы булуын да искәртте Илбашы. «Аның ни икәнен бик яхшы беләбез. Җирләр бүлеп бирергә, башка техник мәсьәләләрне хәл итәргә кирәк. Мондый юлны төбәк башлыкларының нәтиҗәле эшчәнлегеннән башка ачып та булмас иде», – диде Президент.

Яңа юлны беренчеләрдән булып Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов сынап карады. М12 трассасының республика аша узучы өлешенең әзер булуын ил Президентына җиткергәнче үк, ул, Татарстанда җитештерелүче «Аурус» автомобиленә утырып, олы юлга чыккан. Рульдә барганда, Рөстәм Миңнеханов юлның сыйфатын бәяләгән, М12 инфраструктурасын: ягулык салу станцияләрен, туклану пунктларын тикшерү өчен, берничә урында тукталып ясаган. Ә юлның ачылыш тантанасына «КамАЗ»га утырып килде ул.

– Автомобиль трассасының республикага туры килгән җиденче һәм сигезенче өлешләре – 142 чакрым юл, 67 ясалма корылма һәм озынлыгы 3362 метр тәшкил иткән күпер. Бу – бик зур хезмәт. Биредә 5 мең кеше, 1400 данә техника эшләде. Яңа юлны үзем дә сынап карадым. Кичә рульдә Мәскәүгә кадәр бардым. Рәхмәттән ары сүз юк. Мондый юлны күргәнем юк иде әле. Бу – гомумән дә, икенче күзаллау. Барысы да уйланылган: машинага ягулык салырга да, тукланырга да урыннар бар, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Россия Премьер-министры урынбасары Марат Хөснуллин әйтүенчә, мондый хәлнең ил тарихында да булганы юк иде әле.

– Без зур күләмле проектны тормышка ашырдык, – диде ул. – Аны өч ел эчендә башкарып чыктык. Юл төзү идеясеннән аның документларын рәсми рәвештә теркәүгә кадәр өч ел узды. Дөнья күләмендә дә бу кадәр кыска вакыт аралыгында мондый зур проектларны тормышка ашыручылар сирәк.

Марат Хөснуллин сүзләренә караганда, әлеге трасса аның тирә-юнендә яшәүче 50 миллионга якын кешегә кагылачак. «М12 автомобиль юлы аша Мәскәү белән Урал арасында товар әйләнеше, йөк ташу 50 миллион тоннага кадәр артачак дип көтелә. Санкция шартларында Уралга, Көнчыгышка чыгу аеруча мөһим», – диде вице-премьер.

«Татар-информ»

Киләчәк юлы

М12 «Көнчыгыш» югары тизлекле трассасы илнең 5 төбәге – Мәскәү, Владимир, Түбән Новгород өлкәләре, Татарстан һәм Чувашия республикалары аша, ә Татарстанның Кайбыч, Апас, Югары Ослан, Лаеш һәм Питрәч районнары аша уза.

Трассаны алдан фаразлаганнан ярты елга тизрәк кулланышка тапшырдылар. Казан – Мәскәү юлын Екатеринбург, Чиләбе һәм Төмәнгә кадәр озайту турында да карар кабул ителде. Алга таба аны Иркутск һәм Владивостокка кадәр җиткерү, Казахстан, Монголия һәм Кытайга чыгу да күздә тотыла.

Эльвира ВӘЛИЕВА

М12 – саннарда

✓ Юлның гомуми озынлыгы – **810** чакрым.
✓ Рөхсәт ителгән тизлек – **110** км/сәгать.
✓ Мәскәүдән Казанга беренче борылышка кадәр (Р241) юл бәясе җиңел машиналар өчен – **4481** сум.
✓ Төзелеш барышында барлыгы **323** ясалма корылма салганнар.
✓ Биредә **85** меңгә кадәр яңа эш урыны булдырылган.
✓ 2030 елда әлеге юлдан **11300000** пассажир хәрәкәт итәчәк, дип көтелә.
✓ Юлда **19** «ирекле агым» рамкасы урнаштырылган.
✓ Олы юлның Татарстанга туры килә торган өлешләренә хайваннар өчен **7** кичү: җир өстеннән – өч һәм җир астыннан дүрт юл бар.
✓ Төзелеш барышында **370** меңнән артык археологик табылдык ачыкланган.
✓ Юл төзелешенә инвестицияләрнең гомуми финанс нәтиҗәлелеге **1,8** триллион сум күләмендә бәяләнә.

КИЛӘСЕ ЧАКРЫМНАР

Киләсе елда Татарстанда М7 трассасы тулысынча дүрт полосалы булачак. М12 юлы Сокуры авылын урап узу юлы төзелешен ашыктыра. Ә Чулман аша салынучы күпердән Казанга юл кыскарачак. Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ автомобиль юллары федераль идарәсе узып баручы елга йомгак ясады.

Олы юлда эш кайный

– Узып баручы елда төп эшләр М7 «Идел» һәм Р239 Казан – Оренбург трассаларында башкарылды, – диде Федераль юл агентлыгының Идел-Нократ автомобиль юллары федераль идарәсе җитәкчесе Илдар Минһаҗев.

Билгеле булганча, быел М7 трассасында Зөя елгасы аша яңа күпер ачылды. Казан – Оренбург юлында Чулман елгасы аша күпер дә яңарды. Алга таба дәвам иттереләчәк эшләр дә бар. Аерым алганда, М7 юлының Иннополис тирәсендәге өлешендә реконструкцияләү эшләрен киләсе ел азагында тәмамларга ниятлиләр.

Сүз М7 трассасының Югары Ослан районына керүче 761–771 нче чакрымнары турында бара. Биредә төзекләндерү эшләре 2018 елның августында ук башланган.

Сокурыны урыйлар

Илдар Минһаҗев әйтүенчә, башкарылачак төп эшләр 2027 елга кадәр исәпләнгән юл эшчәнлегенең бишьеллык планына кертелгән. Аның кысасында Лаеш районында урнашкан Сокуры авылын урап узу юлын да салачаклар. Биредә төзелешкә әзерлек эшләре башланган да инде. Юлчылар җир казу, коммуникацияләрне күчерү, төзелеш өчен кирәкле ярдәмче юллар салу кебек әзерлек эшләре белән мәшгуль.

– Төп эшләр киләсе елның март – апрель айларында башланачак. Юлны 2025 елда салып бетерергә тырышачакбыз, – диде идарә җитәкчесе.

Аның әйтүенчә, Р239 Казан – Оренбург юлының 20дән 43 нче чакрымга кадәр аралыгы (урап узу юлын салу да шунда керә) реконструкцияләнәчәк. Төзелеш бәясе – 19 миллиард 253 миллион сум. Проектны тормышка ашыру 2025–2027 елларга билгеләнгән. Шул ук вакытта, килешүдә эшләрне алданрак башлау мөмкинлеге дә каралган, дип тә ачыклык кертте Илдар Минһаҗев.

– М12 ачылгач, Сокуры ягына таба машиналар хәрәкәте тагын да көчәячәк, биредә хәзер үк кыенлыклар бар инде, – диде Илдар Минһаҗев, төзелешне тизләтүнең сәбәпләрен аңлатып. – Шунысын да әйтик: М12 аша машиналар хәрәкәте тиз генә артмаячак: машина йөртүчеләрнең яңа юлга да, бәяләргә дә ияләшәсе бар әле. Ул арада без реконструкцияне төгәлләячәкбез.

Төзелеш эшләре аэропорт юлына борылыштан башланып Державино авылына кадәр дәвам итәчәк.

– Юл төзелешенә 130дан артык шәхси җир кишәрлеге дә эләгә. Сүз 107 гектарга якын мәйдандагы җир турында бара. Күпчелеге – шәхси торак төзелешләре. Җир кишәрлекләрен сатып алу милек хуҗалары ризалыгы белән башкарылачак. Моның өчен 900 миллион сум акча каралган, – диде Илдар Минһаҗев.

Кыйммәтле күпер

Киләсе елда Казан – Түбән Кама арасы бер сәгатькә якынаячак дип тә көтелә. Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап узу юлы төзелеп беткәч, әйләнгечтән юл турырак та, тизрәк тә булачак. Биредә эш 2022 елның гыйнварында башланды, төзелешнең әзерлек дәрәҗәсе – 42 процент. Урап узу юлын салу барышында Чулман елгасы аша гына да 23 миллиард сумлык күпер салалар. Аның аша машиналар киләсе ел ахырында ук хәрәкәт итә башлаячак дип фаразлана.

Зөһрә
САДЫЙКОВА

КАДЕРЛЕ КЕШЕЛӘР

Авыл гөрләп яшәсен өчен, халкының эш белән дә, аш белән дә тәэмин итәрлек шартлары булырга тиеш. Әтнә районының Түбән Бәрәскә авылына баргач, моңа кабаттан инанып кайттым. Түбән Бәрәскә – районда иң төзек, матур, эшле авылларның берсе. Халкының күпчелеге шушы җирлектәге алдынгы хуҗалык – Ленин исемендәге нәселле терлек заводында эшли. Төенчеген төйнәп, аны сыртына асып, бәхет эзләп читкә чыгып китмәгәннәр. Туган авылларында кадерле һәм кирәкле кешеләр булып яшиләр. Хуҗалыкның уңыш сере нидә? Аның көчле һәм абруйлы җитәкчесе Илгиз Хәйруллин белән шул хакта фикерләштек.

Уңышлы хуҗалык

Бүген хуҗалыкның 8300 гектар җире бар, аның 7 мең гектары – сөрүлек җирләре. Яңа, заманча фермаларда 3800 мөгезле эре терлек тоталар, шуларның 1500е – сыерлар. Тәүлегенә 43 тонна сөт тапшыралар. Иң мөһиме – авылның 240 кешесе хуҗалыкта эшли.

– Авыл халкы үз авылында кирәкле булырга тиеш, – ди хуҗалык җитәкчесе Илгиз Хәйруллин бу уңайдан. – Безнең фермаларда да сыерларны роботлар сава, язгы кыр эшләрен дә азрак кеше белән башкарып чыга алыр идек. Ләкин безнең кешеләрне эшле итәсебез килә. Механизатор тракторын куеп, бер-ике көн эшсез тора икән, аны шунда ук әләктереп алырга мөмкиннәр. Ә инде яхшы хезмәт хаклары да вәгъдә итсәләр, аны инде кире кайтарып булмаячак. Бүген юрист, экономист һәм башка һөнәр ияләре бик күп, ә менә шофер, тракторчы, слесарь, эретеп ябыштыручылар җитми, чөнки заманында эшче профессияләрнең дәрәҗәсен төшерделәр. Ә бездә ел саен икеөч кеше кала әле.

Читкә китеп йөрмәсеннәр өчен, хуҗалык яхшы хезмәт хаклары белән җәлеп итә. Яшьләр беренче елда ук хезмәт хакына 20 процент өстәмә ала. Киләчәктә эшчеләргә йортлар салу турында да хыяллана Илгиз Хәйруллин.

– Авыл хуҗалыгында терлекчелеге дә, игенчелеге дә булырга тиеш. Игенчелектә билгеле бер вакытта гына акча эшләп була, эшчегә дә эш язын, җәен, көзен генә бар. Ә терлекче ел буе эшлә дә, ашлы да. Бездә эшләүчеләрнең уртача яше – 47. Кызганыч, кызлар азрак. Алар калмый дип, егетләр дә читкә китә. Ләкин бу проблема безнең заманда да бар иде. Ул елларда да калганы калды, китәсе китте, – ди ул.

Хуҗалыкның аягында нык басып торуын аның кредитларсыз гына яшәве дә дәлилли. 5 ел эчендә 800 млн сумлык төзелеш эшләре барган биредә. Ике зур комплекс сафка баскан.

> – Без үзебезне уңышлы эшләп килә торган хуҗалык дип исәплибез. Заманалар ничек кенә авыр булса да, табыш белән эшли алабыз. Хуҗалык бер тиен кредит алмыйча, бөтен эшләрне үз хисабына башкарды.

Мөселман кешесенә, бердән, кредит алу хупланмый. Икенчедән, заманалар үзгәреп тора. Син бер төрле планлаштырырсың, башкача килеп чыгар. Әйтик, быел сөт хаклары төшеп китте. Ягулык, төзелеш материаллары, техника, запас частьлар бәяләре ничек өскә сикерде. Ә хезмәт хакын арттырырга, кешене тотарга кирәк, – ди Илгиз Хәйруллин.

Хуҗалыкта эшләүчеләрнең уртача хезмәт хакы 43 мең сумны тәшкил итә.

Зөлфия Хәлиуллина

Ләйлә Шәрәфетдинова, Әлфия Кадыйрова һәм Ләйлә Уткина эшләрен дә, авылны да яратып яшиләр.

Чәчү, урып-җыю вакытларында бу күрсәткеч ике тапкыр арта.

– Тырыш, булдыклы кыр батырлары 120 мең сумга кадәр хезмәт хакы алдылар. Бездән: «Акчаны аз түлисең», – дип киткән кеше юк. Авылдашлар өчен мәктәптә укучы баласына Казаннан бер яки ике бүлмәле фатир алып кую – гадәти күренеш, – дип елмая җитәкче.

Нинди генә көчле хуҗалык булса да, һәр чорның үз авырлыгы бар. Тик Илгиз Хәйруллин алар турында сөйләргә яратмый.

– Проблемаларсыз гына булмас инде ул, иң мөһиме: алар хәл ителә, – ди ул. – Эшне яратып эшләмәсәм, 33 ел монда була алыр идемме икән? Хуҗалыкны җитәкли башлаганда 27 яшь иде бит миңа. Энергиянең беткән вакыты да була аның. Әгәр төшенкелек озакка сузылса, җитәкче булып бөтенләй эшләп булмас иде. Шуңа күрә үзеңне тиз арада кулга алырга кирәк.

Эшлисе килеп эшләү

Бүген җирлектә 1362 кеше яши. Шуларның 650се – Түбән Бәрәскә авылында. Бик матур мәдәният йортлары, мәктәпләре, балалар бакчалары (37 бала йөри), китапханәләре, берничә кибетләре, медпункт, данлыклы мәчетләре, ял парклары бар.

– Авыл җирлегенә караган күп мәсьәләләрне Ленин исемендәге нәселле терлек заводы ярдәме белән хәл итәбез, – ди авыл советы башлыгы Аида Фатыйхова. – Авылларыбызда терлек асрау өчен дә мөмкинлекләр зур. Шәхси хуҗалыклар күмәк хуҗалык тарафыннан җитәрлек күләмдә терлек азыгы белән тәэмин ителә.

Безнең авыл җирлегендә 910 баш мөгезле эре терлек бар. Шуның 495е – савым сыерлары. Дәүләткә сөт тапшырып, 11 айга халык 61 миллион сум акча алды. 14 башка кадәр савым сыеры асраучы гаиләләр дә бар.

Шәхси хуҗалыкта савым сыерларын саклау максатыннан уздырылган республика программасы нигезендә терлек асраучыларга быел барлыгы 2 миллион 722 мең 508 сум субсидия бирелде.

Ферма кызлары

Элек авылларда «ферма кызлары»ның зур даны, абруе бар иде. Шөкер, алар бүген дә төшеп калганнардан түгел. Эшләрен һәм авылларын яратып, гөрләтеп яшәп яталар. Бүген хуҗалыкта 26 сыер савучы эшли. 23 елдан артык эш стажы булган Ләйлә Уткина да юкка гына авылда калырга булмаган.

– Әти-әни гомер буе колхозда эшләде, шуңа күрә үземнең дә авылда каласым килде. Яңа комплексларда, яхшы шартларда эшлибез. Элек кул хезмәте күп иде. Хәзер анысы азрак, ләкин саварга сыерлар күбрәк. Акчаны вакытында бирәләр, эшкә барасы килеп барабыз. Авылда хезмәт хакы аз, дип уйларга кирәкми, шәһәрдә дә бар җирдә дә артыгын бирмиләр. Ирем шушында ук оператор булып эшли. Ул да яхшы акча ала. Җитәкчебезнең терлекчеләргә карата хөрмәте бик зур. Бүләкләрен дә мулдан бирә, рәхәтләнеп ял да иттерә белә. Хезмәте дә авыр, хөрмәте дә бар. Без канәгать, – ди ул.

Ләйлә апаның гаиләсендә ике бала үсеп килә. 10 яшьлек уллары инде бүгеннән үк: «Теләсә нәрсә эшләгез, тик мин авылда калам», – дип әйтә икән.

– Авылда бик рәхәт безгә. Үзебезгә дә, балаларга да барлык мөмкинлекләр бар. Кая телиләр, шул түгәрәкләргә йөриләр. Авылның һәр мәшәкатен яратам. Фермадан кайткач, өйдәге малларны карарга да бик теләп чыгам. Бозауларын көтеп алам. Сөтләре әйбәт булса, күңел үсә. Акчасын көнендә бирәләр. Күпме хезмәт керсә дә, акчасын алганда «күктән төшкән керем» дип кабул итәбез. Тизгә генә булса да Казанына да барып кайтабыз. Башка авылларга концертлар белән дә йөрибез, – ди ул.

Башка сыер савучы апалар – Ләйлә Шәрәфетдинова белән Әлфия Кадыйрова да эшләрен дә, авылны да бик яратып яшәүләрен сөйләделәр.

– Шәһәр тормышы белән авыл тормышын чагыштыру бар инде ул. Бер ара кызыгып та куябыз. Эшен эшлиләр дә ялын ял итәләр, барасы җирләренә баралар, дибез. Ләкин терлек асрамаучылар авылда да нәкъ шулай яши хәзер. Авылның киләчәге юк, дигән сүзләр минем күңелемне кыра. Бар аның киләчәге, нишләп булмасын ди?! Яшьләр кайта бит әле, менә дигән итеп йортларын да салып керә. Шулай булгач, начарын уйлыйсы килми, – ди Әлфия Кадыйрова.

Урта буын гына түгел, ел саен ике-өч кенә булса да яшь-җилкенчәк тә кала авылда. Фермадагы апаларның уң кулы ветврач Илшат Шакиров – әнә шундыйлардан.

– Шәһәрне яратмыйм мин. Анда барган саен башым авыртып кайта. Юллардагы «бөке»ләр җанга тия, ишегалларында машина куярга урын табып булмый. Ә авылда рәхәт, тыныч. Бөтен әйбер бар. Хатыным һәм ике балабыз белән әти-әниләр янында төп йортта яшибез. Аралашырга, гаиләләр белән йөрешергә яшьтәшләребез дә җитәрлек. Әйтик, без мәктәпне 13 кеше бетердек, өчебез авылда калды. Шуңа күрә мин, авылны яманлап, бер генә сүз дә әйтә алмыйм, – ди яшь белгеч.

Менә шулай яшәүнең дә, эшләүнең дә тәмен белеп, бүгенгесенә шөкер итеп, киләчәгенә матур өметләр баглап яши Түбән Бәрәскә халкы.

РУХИ КӨЗГЕ

Бәйге

«Сез иң гүзәл кеше икәнсез!» Укытучылар һәм остазлар елы уңаеннан Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе «Казан утлары» журналы редакциясе белән берлектә әнә шундый татарча әдәби әсәрләр конкурсы оештырган иде. Ниһаять, без җиңүчеләрне белдек.

«Татар-информ»

Җиңүчеләр арасында «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррир урынбасары Гөлинә Гыймадова да бар. Аның «Усал» повесте өченче урын алды.

Бәйгегә килгән әсәрләр балаларга белем һәм тәрбия бирүче укытучыларга, татар халкының милли мәгариф тарихына, мәктәп тормышына багышланган. Анда Ульяновск өлкәсе, Башкортстан, Удмуртия, Чувашия, Татарстанда яшәүчеләр генә түгел, хәтта Сүрия, Төркиядәге милләттәшләр дә каләмен сынап караган.

Татарстан Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе Марат Әхмәтов җиңүчеләрне бүләкләү тантанасында Укытучылар һәм остазлар елының әһәмиятенә тукталды. Киләсе елда да укытучы һөнәренә аерым хөрмәт күрсәтеләчәгенә, аларның җәмгыять тарафыннан да зуррак бәяләнергә тиешлеген әйтте.

– Балачак, мәктәп елларын яшь барган саен күбрәк сагынабыз. Безнең чорда укытучы җәмгыятьнең, авылның, тормышның рухи идеалы кебек кабул ителә иде. Һәркем, укытучы кебек булсам иде дип, шуңа охшарга тырышты. Әмма соңгы 30–40 ел эчендә илебездә тормыш кыйммәтләре үзгәрде. Шушы рухи кыйммәтләрне, шул ук вакытта укытучының җәмгыятьтәге җаваплылыгын да күз алдында тотып, быел Укытучылар һәм остазлар елы дип игълан ителгәндер дип уйлыйм, – диде ул.

Марат Әхмәтов үзенең мәктәп еллары, әнисе – беренче укытучысы турында да горурланып сөйләде. Авыл халкының, әти-әниләрнең мөгаллимнәргә мөнәсәбәтен дә яхшы хәтерли ул. Ул елларда: «Укытучы да бәрәңге ашыймыни?» – дип гаҗәпләнүләрен искә алды.

Әнисенә карата да җылы мөнәсәбәтен белдерде Марат Әхмәтов. «Беренче укытучым – әнием, сөбханалла, исәнсау. Бүген 99 нчы яше белән бара. Күзе күрә, акылы төзек. Әниебез хәтта газета укый, телевизор карый», – диде ул, олы хөрмәт белән.

Аның фикеренчә, укытучыга мөнәсәбәт – җәмгыятьнең рухи көзгесе. Укытучыны үрнәк шәхес дип бәяләгән җәмгыять рухи яктан чиста һәм сәламәт дигән сүз. «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Рөстәм Галиуллинга шундый матур бәйге игълан иткән өчен рәхмәтен белдереп: «Укытучы образын без киләчәктә дә күтәрергә тиеш», – диде ул.

Рөстәм Галиуллин исә конкурс ярдәмендә укытучыны хөрмәтли, мәгариф системасындагы проблемаларны яктырта алуларын әйтте. Димәк, максатка ирешелгән.

«Повесть» номинациясендә беренче урын, «Сары атым алтын нукталы» әсәре өчен, Аксубай районының Яңа Дума авылыннан килгән Әлфирә Галиевага бирелде. Хикәя номинациясендә исә Ркаил Зәйдулла «Кани калды Нишапур» әсәре белән беренче булды. Балалар да тырышкан. Алар арасында җиңүче дип Теләче районындагы Баландыш авылының 9 нчы сыйныф укучысы Назлыгөл Гайнетдинова табылды.

Бүләкләр тапшырылып беткәч, Марат Әхмәтов үзен кызыксындырган сорауларны бирде: «Иҗат эшегез сезнең язмышка йогынты ясаган укытучылар турындамы? Җыелма образлар түгелме?» Бәйгене оештыручылар: «Чынбарлыктагы кешеләр», – диде. Комиссия рәисе, киләчәктә бу геройларны бергә җыеп булмасмы, дигән фикер дә әйтте.

Сәрия МИФТАХОВА

ТЫЙНАК БАТЫРЛЫК

РЕСПУБЛИКА ТАБИБЛАРЫ УНИКАЛЬ ОПЕРАЦИЯЛӘР ЯСЫЙ

Татарстан табиблары шаккатыра. Республика клиник хастаханәсе табиблары, авыру ир-атның бавырын алып, паразитлардан чистарткан һәм кабат урынына куйган! Бу көннәрдә әнә шундый искиткеч хәбәр таралды. Башкала табибларының батырлыгына сокланырга да өлгермәдек, Мамадышта да уникаль операция ясаулары билгеле булды.

Республика клиник хастаханәсе

РКБ табиблары тудырган могҗизалар турында әледән-әле ишетеп торабыз анысы. Әмма бу юлы алар бөтенләй башка төрле катлаулы операция ясаган. Авыру ир-атның эченнән бавырын алып, шуны паразитлардан чистарткан да кабат урынына куйган алар! Мондый уникаль операциягә бүген Россиянең өч шәһәрендә – Мәскәү, Түбән Новгород һәм Новосибирскида гына алыналар иде. Республика табибларының батырлыгы ярдәмендә хәзер аны Татарстанда да ясап булачак.

Могҗиза белән исән калган Сергей Пушкин алты елдан бирле бөерендә үзгәреш барын сизеп яшәгән. Әмма шул вакыт эчендә бер тапкыр да табибка күренмәгән, соң чиккә җиткәч кенә, хастаханәгә барырга булган.

– Соңгы елларда үземдә гел хәлсезлек сизә идем. Йокысызлыктан интектем. Күңел төшенкелегенә биреләдем, – ди ир-ат үзе.

Иң элек табиблар аның бөерендә яман шеш юкмы икәнлеген тикшергән. Әмма бу шикләре расланмаган. Тикшерә торгач, ир-атның бавырын паразитлар камап алганлыгы ачыклана. Аңа альвеококкоз диагнозы куела.

РКБның 2 нче хирургия бүлеге җитәкчесе Ленар Җиһаншин сүзләренә караганда, паразитлар ир-атның юан кан тамырларына кадәр үк зарарлаган була. Нәтиҗәдә ул урында бик зур шеш барлыкка килгән.

– Бавыр бик нык зарарланганга күрә, операцияне эчтә ясау хәтәр иде. Шуңа күрә бавырны ир-атның эченнән алып чистартырга карар кылдык. Иң элек компьютер томографиясе ярдәмендә, кеше исән калсын өчен, аның бавыры никадәр зурлыкта булырга тиешлеген исәпләп чыгардык. Аннары әгъзаны тулысы белән боз эченә салдык. Аның зарарланган өлешен кисеп алып, бавырны паразитлардан чистарттык та кире үз урынына урнаштырдык, – ди герой табиб.

Шул рәвешле республикада югары дәрәҗәдәге, моңа кадәр ясалганнарыннан күпкә катлаулырак трансплантация башкарыла. Кешегә донор әгъзасын түгел, ә чистартылган үз бавырын утыртканнар! Катлаулы операция 13 сәгать (!) дәвам иткән.

Беренче коймак уңышлы чыга. Сергей операциядән соң бер атна реанимация бүлегендә яткан. Аннары бик озак тернәкләнгән. Хәзер инде аның хәле яхшырган. Бу атнада Сергейны өенә кайтарырга җыеналар.

Мамадыш

Башкала табиблары тудырган могҗизага гаҗәпләнергә дә өлгермәдек, Мамадышта да уникаль операция ясаулары ачыкланды. Ерак юлдан өенә кайтып барган ир-атның рульдә барганда кисәк кенә хәле начарлана. Бәхеткә, аңын югалтканчы туктап өлгерә ул. Янында утырып барган улы тиз арада ашыгыч ярдәм чакыра. Йөзе агарган, тәненнән салкын тир бәреп чыккан аңсыз ир-атны тиз арада Мамадыш үзәк район хастаханәсенә алып киләләр.

Хастаханәнең хирургия бүлеге мөдире Нияз Мифтахетдинов сүзләренә караганда, ир-атны җентекләп тикшерә алар. Ике-өч тапкыр компьютер томографиясе ясыйлар. Ни гаҗәп, өчесе өч төрле нәтиҗә күрсәтә. Ул арада ир-атның хәле авырайганнан-авырая бара. Нияз Мифтахетдинов тиз арада Чаллы шәһәренең Ашыгыч медицина ярдәме хастаханәсенең кан тамыры хирургы белән киңәшләшә. Соңрак ир-атның бавырында шеш барлыгы, корсак куышлыгына кан сауганлыгы ачыклана.

– Аңа тиз арада катлаулы операция ясарга кирәк иде. Үзебезнең көч кенә җитмәячәкне аңлап, ярдәм сорап, якташыбыз – РКБның 2 нче хирургия бүлеге җитәкчесе Ленар Җиһаншинга шалтыраттык. Гадәттән тыш хәл, һәр минут исәптә, һава торышы начар, авыруны урыныннан кузгатырга ярамый... Шуңа Ленар Илдарович районга үзе кайтырга булды. Кан салырга кирәк булса да, әзер торсын дип, РКБ белән Чаллыдагы хастаханәгә ике машина җибәрдек, – ди Нияз Мифтахетдинов.

Ленар Җиһаншин Мамадышка кайтып җиткәндә, авыру операция өстәлендә була. Нияз Мифтахетдинов белән бергә дүрт сәгать дәвамында уникаль операция ясый алар. Бавырдагы шешне алып, кан китүне туктатып калалар.

– Монда һәр секунд исәптә иде. Сүз белән түгел, күз белән аңлаштык. Аллаһка шөкер, операция уңышлы чыкты. Бер тәүлек дигәндә, ир-ат мөстәкыйль рәвештә сулый башлады. Ун көннән инде аны өенә чыгардык, – ди табиб.

Уникаль операция ясаган кайсы гына табиб белән сөйләшмә, берсе дә моны ниндидер батырлыкка санамый, үзенең төп бурычын үтәү дип кенә атый. Кайчак хәтта нинди могҗиза тудыруларын үзләре дә аңлап бетерми кебек тоела. Сигез ел элек, вузны тәмамлауга ук, туган ягы Мамадышка кайткан Нияз Мифтахетдинов та тыйнак кына: «Тәҗрибәмдәге шундый беренче катлаулы очрак бу. Аллаһка шөкер, хәерле тәмамланды», – дип кенә куйды. Ә бит әле берничә ел элек кенә бугазы, ашказаны кискәләнеп беткән ир-атны сәгатьләр буе кисәкләп җыйган булган ул...

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

25 декабрь | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.05 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 20.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30, 16.00 «Халкым минем…» 12+
12.00, 22.40 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР» 16+
13.00 «Семь дней» 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.45 «Семь дней +» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «Сөйләшергә вакыт» 16+
17.40 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Кто мы татары?» 12+
19.00, 01.40 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Заман көзгесе» 6+
22.00 «Вызов 112» 16+
22.10 «Реальная экономика» 12+
23.30 «ЖЁЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА» 16+
00.25 «Ә син…?» 16+
01.00 «Каравай» 6+
01.25 «Путь» 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00, 00.15 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней» 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05, 18.20, 22.15 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
12.35 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Заман көзгесе» 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
18.50, 22.40, 02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.35 «Әниемнең җылы кочагы» 16+
20.30 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
21.55 «Туган авылым» 12+
00.40 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
03.30 «Таз малай, әкиятче бабай – Хәлим Җәләй» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Россия и Запад на качелях истории» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Летописи конца времен» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-23» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
04.05 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «География спорта» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 03.55 Новости 0+
07.05, 23.15 Все на Матч!
10.05 «Лица страны. Руслан Захаров» 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Сирил Ган против Джона Джонса 16+
12.35, 03.35 Специальный репортаж 12+
13.00 «Есть тема!»
14.25 «Здоровый образ. Борьба» 12+
14.55 Хоккей. OLIMPBET Чемпионат МХЛ. «Толпар» – «Чайка»
17.15 «Громко»
18.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Динамо» – СКА
21.45 Бильярд. «BetBoom Суперлига»
00.15 Профессиональный бокс. RCC. Магомед Исмаилов против Ивана Штыркова 16+
01.35 Баскетбол. Единая лига ВТБ. УНИКС – «Самара» 6+
04.00 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Виктор» – «СКА Минск» 6+
05.30 Аквабайк. Чемпионат мира по гонкам на выносливость 6+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ЛИХАЧ» 16+
22.10 «БИМ» 16+
00.50 «ШПИОН №1» 16+
02.35 «АДВОКАТ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
06.55 «Давай разведёмся!» 16+
07.55 «Тест на отцовство» 16+
10.00, 23.00 «Понять. Простить» 16+
11.05, 00.05 «Порча» 16+
12.10, 01.05 «Знахарка» 16+
12.50, 01.35 «Верну любимого» 16+
13.25, 02.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.00 «Новый год по-домашнему» 16+
14.30 «ПОКА ВСЕ ДОМА» 16+
19.00 «РОКОВАЯ ОШИБКА» 16+
02.30 «ПОЗДНИЙ СРОК» 16+
05.40 «6 кадров» 16+
06.05 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «БЕЗ ПРАВА НА ОШИБКУ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
11.15 «БОЛЬШАЯ ПЕРЕМЕНА» 12+
12.45, 13.25, 03.35 «УЧАСТОК ЛЕЙТЕНАНТА КАЧУРЫ» 16+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «105 дней незаменитой войны» 18+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Ищу своих» 12+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «РОССИЯ МОЛОДАЯ» 12+
01.45 «В ДОБРЫЙ ЧАС!» 12+

26 декабрь | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 02.00 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
10.00, 20.00 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте»
11.15, 01.00 «Если хочешь быть здоровым» 16+
11.30, 16.00 «Татарлар» 12+
12.00, 22.10 «МӘХӘББӘТ ҺӘМ ЙОЛДЫЗЛАР» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45, 21.00 «Семь дней+» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә 0+
16.30 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ 2» 16+
17.30 «Заман көзгесе» 6+
18.00 «Казаннан – Казанга» 16+
19.00, 03.30 «Таяну ноктасы» 16+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.00 «ЖЁЛТЫЙ ГЛАЗ ТИГРА» 16+
00.00 «Җыр пеш!» 16+
00.35 «Видеоспорт» 16+
01.15 «Башваткыч» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
04.45 «Кәмит Җәвит» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Үткәннәр сагындыра» 12+
08.30, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
10.00 «Күңелләрдә тальян моңнары» 12+
10.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30, 16.30, 20.30 «Таяну ноктасы» 16+
12.05, 18.20, 22.15 «7 ЮЛ ЧАТЫНДА» 16+
15.25, 03.05 «Әдәби хәзинә» 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
20.00 «Халкым минем» 12+
21.25 «Ком сәгате» 16+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.40 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә» 16+
05.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 «Доброе утро»
09.00, 12.00, 15.00, 03.00 Новости
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50, 17.00 Информационный канал 16+
15.15 «Давай поженимся!» 16+
16.05 «Мужское / Женское» 16+
18.00 Вечерние новости
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «ДОКТОР ПРЕОБРАЖЕНСКИЙ» 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
00.45 ПОДКАСТ.ЛАБ «Драгоценные истории» 16+
01.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Не лыком шиты» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гори огнем!» 16+
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время
09.55 «О самом главном» 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30, 17.30 «60 минут» 12+
14.55 «Наши» 12+
16.30 «Малахов» 16+
21.20 «ТАЙНЫ СЛЕДСТВИЯ-23» 16+
23.30 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 «СКЛИФОСОВСКИЙ» 16+
04.05 «МОРОЗОВА» 16+

МАТЧ ТВ

06.00 «Спортивный век» 12+
06.30 «Магия большого спорта» 12+
07.00, 10.00, 12.55, 14.55, 18.00, 03.55 Новости 0+
07.05, 15.00, 18.05, 21.15, 23.15 Все на Матч!
10.05, 12.35, 03.35 Специальный репортаж 12+
10.25 «Лучшие из лучших» 12+
11.25 Смешанные единоборства. UFC. Алекс Перейра против Исраэля Адесаньи 16+
12.15 Смешанные единоборства. UFC. Иржи Прохазка против Алекса Перейры 16+
13.00 «Есть тема!»
14.25 «Что за спорт?» 12+
15.30 Дартс. OLIMPBET Новогодний марафон
18.45 Хоккей. Фонбет Чемпионат КХЛ. «Торпедо» – «Спартак»
21.45 Бильярд. «BetBoom Суперлига»
00.15 Профессиональный бокс. URAL FC. Альберт Батыргазиев против Эндера Луцеса 16+
01.35 Баскетбол. Единая лига ВТБ. «МИНСК» – ЦСКА 6+
04.00 Гандбол. SEHA-Газпром Лига. «Зенит» – «Мешков Брест» 6+
05.30 Аквабайк. Чемпионат мира по гонкам на выносливость 6+

НТВ

04.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25 «ПЁС» 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» 16+
17.50 «ДНК» 16+
20.00 «ЛИХАЧ» 16+
22.10 «БИМ» 16+
00.50 «ШПИОН №1» 16+
02.35 «АДВОКАТ» 16+

ДОМАШНИЙ

07.30 «Давай разведёмся!» 16+
08.30 «Тест на отцовство» 16+
10.35, 23.00 «Понять. Простить» 16+
11.40, 00.05 «Порча» 16+
12.45, 01.05 «Знахарка» 16+
13.20, 01.35 «Верну любимого» 16+
13.55, 02.05 «Голоса ушедших душ» 16+
14.30 «Твой Домашний доктор» 16+
14.45 «НАЙДИ МЕНЯ, СЧАСТЬЕ» 16+
19.00 «МОЯ СЕСТРА ЛУЧШЕ» 16+
02.30 «СЕМЕЙНЫЙ ПОРТРЕТ» 16+
05.30 «6 кадров» 16+
05.45 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.15, 12.45, 03.35 «УЧАСТОК ЛЕЙТЕНАНТА КАЧУРЫ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 17.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15, 21.00 «Открытый эфир» 16+
11.00, 18.50 «Специальный репортаж» 16+
11.15 «БОЛЬШАЯ ПЕРЕМЕНА» 12+
15.00 Военные новости 16+
18.00 «105 дней незаменитой войны» 18+
19.55 «По горячим следам» 16+
20.10 «Улика из прошлого» 16+
22.45 «Между тем» 12+
23.15 «РОССИЯ МОЛОДАЯ» 12+
01.35 «МЕДОВЫЙ МЕСЯЦ» 12+
03.10 «Москва фронту» 16+

КАЙГЫ УРТАКЛАШУ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Аппараты матбугат хезмәте җитәкчесе **Резида Галимҗан кызы МАКУЕВАның** кинәт вафат булуы сәбәпле, мәрхүмәнең гаиләсе һәм якыннарының олы кайгысын уртаклаша. Хезмәттәшләре һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре арасында зур абруй казанган, Татарстан журналистикасын үстерүгә үзеннән саллы өлеш керткән талантлы җитәкче арабыздан мәңгегә китте. Профессиональ осталыгы һәм кешеләргә карата игътибарлы мөгамәләсе нәтиҗәсендә ул халык арасында зур ихтирам-хөрмәткә лаек булды. Изге күңелле коллегабыз, сөекле ана, кайгыртучан әби, ышанычлы дустыбызны югалту турында кайгылы хәбәр безне нык тетрәндерде. Резида Галимҗан кызы Макуеваның якты истәлеге күңелләребездә мәңгегә сакланыр.

«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе коллективы, Татарстан Дәүләт Советы матбугат хезмәте җитәкчесе **Резида Галимҗан кызы МАКУЕВА** вафат булу сәбәпле, гаиләсенең, якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

«Татмелиорация» траст компаниясе» ачык акционерлык җәмгыяте мелиораторлары коллективы һәм җитәкчелеге, этисе **Илшат Мәҗит улы ИДРИСОВның** кинәт вафат булуы сәбәпле, Рамил Илшат улы Идрисовның, гаиләсе һәм якыннарының авыр кайгысын уртаклаша.

«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА

РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65,
222-09-70.

E-mail: vtreklama@mail.ru

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ЧАМА КИРӘК

Узып баручы елның санаулы көннәре генә калды. Яңа елны ничек каршылау, табында ниләр булачагын акрынлап планлаштыра башларга вакыт. Бәйрәм кичен сау-сәламәт уздыруның сере нидә? Озын бәйрәм еллары табиб бусагасын таптап үтмәсен өчен, нинди кагыйдәләрне истә тотарга кирәк?

Табиб-терапевт, гастроэнтеролог Индира ГЫЙМАЛТДИНОВА шул уңайдан киңәшләр бирде.

Кайберәүләр бәйрәм алдыннан, бушанам дип, ач тора. Бу – бик зур хата. Озак вакыт ашамый торып ашаганда ашказанына икеләтә зур зыян килә. Шуңа күрә бәйрәм алдыннан тамагыгыз тук булсын. Бәйрәм алдыннан үз-үзеңә: «Еллардан соң диетага утырам», – дип вәгъдә итәргә дә ярамый. Ник дигәндә, шул хакта уйлап, бәйрәм кичендә артыгын ашап ташлавыгыз бар.

Бәйрәм чорында иң беренче чиратта ашказаны, эчәк авырулары баш калкыта. Шуңа күрә бу чорда безгә күбрәк эч авырту, сару кайнау, кикергәндә ачы су килеп тилмертү, эч кату, күңел болганудан зарланучылар мөрәҗәгать итә. Гастрит, үт куыгы белән ашказаны асты бизе ялкынсынудан тилмергән кешеләр Яңа ел ялларында аеруча сак булсын иде.

Артык килограммнар җыймас өчен, ач карынга исерткеч эчемлек эчүдән саклаus.

Артык килограммнар җыймас өчен, ач карынга исерткеч эчемлек эчүдән сакланыгыз. Хәмер калориягә бай булуыннан тыш, аппетитны ача, организмнан су чыгуны тоткарлый. Исерткеч эчемлек кулланган кеше күпме ашаганын да белештерми.

Ризык янында артык озак утырып, басып, ятып торырга да киңәш итмәс идем. Үзегезгә берәр шөгыль табасызмы, биисезме, якыннарыгыз белән аралашып, йә булмаса телевизор карап ял итеп аласызмы – мөһим түгел. Иң мөһиме – өстәл янынннан вакытында китә белергә кирәк.

Десерттан баш тартыгыз. Төнгә каршы баллы ризык ашау – организм өчен зур сынау.

Кунакта хуҗалар кыстаган саен, «яхшы түгел» дип, тәлинкәгә салган бар ризыкны ашап бармагыз. «Юк» дип әйтә белегез.

vk.com

Бәйрәм көнне дә гадәттәгечә 1,5–2 литр су эчәргә онытмагыз.

Бәйрәм ялларында көнгә 4–5 тапкыр аз-азлап ашасаң, хәерле. Бер ашау белән икенче ашау арасында өч сәгать аерма булсын. Табын янында җыелган калорияләрне чана, чаңгы, тимераякта шуып «яндырырга» тырышыгыз.

Мөмкинлек булса, кечкенә тәлинкәдән ашарга тырышыгыз. Анда салынган ризык карап торышка бик күп кебек тоелса да, чынлыкта сез бик аз күләмдә ашаячаксыз. Баш миендә туклык хисе тусын өчен, 20 минут вакыт кирәк. Шуңа күрә ризыкны яхшылап чәйнәп, ашыкмыйча гына ашагыз.

Игътибар иткәнегез бардыр: бәйрәм табыны янында, гадәттә, берәүләр сөйләгәндә, икенчеләре тыныч кына ашавын белә. Кыенсынып утырмагыз, әңгәмәгә сез дә кушылыгыз. Җанлы аралашу ризык белән генә мавыгырга ирек бирмәс.

Ишеттегезме?

Корвалолны тыймакчылар

Россиядә корвалол һәм валокордин сатуны тыярга кирәк! Табиб-кардиолог, геронтолог һәм гериатр Юрий Конёв бу көннәрдә шундый тәкъдим белән чыккан. Конёв сүзләренчә, корвалол һәм валокордин кайбер очракларда сәламәтлеккә зыян гына салырга мөмкин. «Бу даруларның нигезен йоклата торган һәм седатив (тынычландыручы) матдәләр тәшкил итә. Алар йөрәкнең кан тамырларына берниндн йогынты ясамый», – ди табиб. Конёв сүзләренчә, мондый препаратларны йөрәк өянәкләре вакытында кабул итү аеруча куркыныч. Аларны эчкән кеше тынычлана, авырту басылгандай тоела, ә процесс дәвам итә һәм бу аяныч нәтиҗәләргә китерергә мөмкин. «Корвалол белән валокординны күпләр йөрәк авырулары вакытында файдалы дип исәпләсә дә, рәсми рәвештә алар йөрәк дарулары дип саналмый», – ди ул.

Аз йоклау симертә

«JACC» медицина журналында күптән түгел бик кызыклы тикшеренү нәтиҗәләре басылып чыккан. Анда йокы туймау һәм симерүнең үзара бәйләнеше ачыклана. Галимнәр уздырган әлеге тикшеренүдә 19–39 яшьләрдәге 12шәр кешедән торган ике төркем катнашкан. Аларны 21 тәүлеккә сырхауханәгә урнаштырып, бер төркемдәгеләргә тәүлегенә 4–5 сәгать кенә, ә

икенче төркемгә 9 сәгать чамасы йоклау мөмкинлеге бирелгән. Шул ук вакытта алар җаны теләгән кадәр ашый алган. Тәҗрибәдә катнашучыларның күпме күләмдә ашавын, кулланылган калорияләрен, май тукымасы күләмен һәм аның бүленешен, шулай ук энергия сарыф итү дәрәҗәсен контрольдә тотканнар. Нәтиҗәдә аз йоклаган кешеләр 21 көн эчендә шактый авырлык җыярга өлгергәннәр. Йокысы туйганчы йоклаучылар исә ашау белән артык мавыкмаган, аларның гәүдә авырлыгында да сизелерлек үзгәрешләр күзәтелмәгән.

Саклап куй!

Бушанасы да булачак

Тәмле ризыклар, тәм-том белән тулы озын-озак еллардан соң бушану көннәре дә ясап алырга туры киләчәк.

Алмалы бушану. Көненә 5–6 тапкырга бүлеп, 1,5–2 килограмм алма ашарга кирәк. Алманың 1/3 өлешен пешереп ашау да файдалы булачак. Чөнки пешкән алмада пектин күбәя. Ә ул исә, үз чиратында, организмнан шлак һәм холестеринны яхшы чыгара.

Кефирлы бушану. Көн буена 2 литр майсызландырылган кефир эчәргә мөмкин. Шулай ук аңа яшел тәмләткечләр белән кыяр да өсти аласыз. Кефир авырлыкны гына көйләп калмыйча, иммун системасын да ныгыта.

Йогыртлы бушану. Майлылыгы 2,5% булган 8–10 стакан йогырт эчәргә киңәш ителә. Саклану вакыты ике атнадан артмаган йогыртны сатып алырга кирәк.

Табигать даруханәсе

ЫЛЫС БУЛЫША

Иммунитетны ныгытыр өчен, нарат, чыршы ылысы белән дуслашырга кирәк. Моның өчен кечкенә эмаль савытта 250 грамм су кайнатыгыз да шуңа әз-әзләп кенә 40–50 грамм нарат яки чыршы ылысы салыгыз. Әгәр ылысны яңа җыйган булсагыз, 20 минут кайнатырга кирәк. Ә инде җәй һәм яз айларында җыелган булса, 40 минут кайнатыгыз. Аннары төнәтмәне сөзегез (ылысларны башта ук марляга төреп салырга да була). Җәй яки яз көннәрендә җыелган ылыс ботакларын суыткычның түңдыру бүлегендә сакларга кирәк.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

БӘЙРӘМ ИСЕ

Мандарин диюгә, борынга Яңа ел исе килеп бәрелгәндәй була. Кояш кебек җете, матур бу җимеш бәйрәм табынының алыштыргысыз сые санала чөнки. Ләкин аның да төрлесе була. Шуңа күрә бу юлы мандарин сайлау серләренә тукталып үтәсе иттек.

КАБЫГЫ. Цитрусның кабыгы никадәр җетерәк төстә булса, җимеше шуның кадәр өлгергәнрәк, димәк, тәмлерәк дип уйлыйбыз. Ләкин, белгечләр әйтүенчә, өлгергән җимеш, кызгылт сары төстән тыш, сап-сары яки хәтта яшькелтрәк тә булырга мөмкин. Шуңа күрә төсенә түгел, ә кабыгына игътибар итәсе: өлгереп җиткәненең кабыгы тизрәк куба. Аннан бармак белән басып карарга да онытмагыз: бик җиңел батып керә икән, җимеш йә бозыла башлаган, йә өшегән дигән сүз.

ТӘМЕ. Татлысын яратсагыз, Израиль һәм Мароккодан китерелгәнен сайлагыз. Марокко җимешләре ваграк, ямьшәйгәнрәк рәвештә була. Ә менә Төркия, Грузия һәм Абхазиядән китерелгәннәре уртача зурлыкта һәм әчкелтемрәк. Шунысы әйбәт: нитратлардан шикләнәсе юк. Ник дигәндә, андагы лимон кислотасы үзе үк җимештәге зарарлы матдәләрне юкка чыгара.

ФАЙДАСЫ. Мандарин Көнчыгышта борын-борыннан цитруслар арасыннан иң файдалысы булып санала. Сәбәбе – канны суыта. Суыту дигәндә, Көнчыгыш аксакаллары канны сыегайтуны күздә тота. Шуңа күрә кан тамырларында тромблар булдырмас өчен кулланыла. Мандарин бавыр эшчәнлеген яхшырта, иммунитетны ныгыта. Ә инде судан, углеводлар һәм азык җепселләреннән генә торуы, ягъни калориясез булуы, организмдагы майны таркатып, ябыгуга китерә. Моннан тыш әле кәефне дә күтәрә.

Белеп тор!

ЧҮЛМӘКТӘГЕ СЫЛУ ХИКМӘТЕ

Яңа елга чүлмәктәге чыршы бүләк итү яки үзеңә сатып алу модага керде. Бик әйбәт бит: башта бәйрәм күрке була да аннан соң чүплеккә ыргытылмый, ә бакчага чыгарып утыртыла. Тик бу – ялгыш фикер. Күпчелек очракта урман сылуы туфракка хәтле барып җитә алмый: корып әрәм була. Чөнки ул өйдәге җылы һәм коры һавага түзми.

Бәйрәмне мондый чыршы янында каршылыйсы итсәгез, торакка аны берничә сәгатькә генә алып керергә мөмкин икәнен онытмагыз. Бәйрәм күркен җылы да, бик суык та булмаган урынга, әйтик, балконга урнаштырыгыз. Чүлмәген иске җылы пальто яки юрган белән әйбәтләп төрегез. Туфрагы кипсә, бераз су сибеп торыгыз. Чыршы тирәсенә әллә нигә бер су бөркегез. Ләкин суны ылысларына тидермәскә тырышыгыз. Болай эшләгәндә, урман сылуы язга кадәр бик яхшы сакланачак һәм аны инде туфракка да утыртып куярга мөмкин булачак.

Тәмле булсын!

Бәйрәм койкасы

Сиринә ЗАРИПОВА рецепты

«Һәр ел саен бәйрәм табынына шушы рецепт белән койка әзерлим. Оливье салаты кебек, бу ризык та үзенә бер Яңа ел символы кебек бит», – дип язып җибәргән безгә Сиринә.

Кирәк: *1,5 кг тавык, сеңерле, сөякле сыер ите (аяк тирәсе – 2 кг чамасы), уртача зурлыкта 1 кишер, 1 баш суган, 6 тырнак сарымсак, 2 дәфнә яфрагы, 6 түгәрәк кара борыч, тәменчә тоз.*

Сөякле итләрне юып, салкын сулы кәстрүлгә салабыз. Суы кайнап чыгар алдыннан күбеген җыеп, тоз салабыз. Салмак кына утта кимендә 5–6 сәгать пешерәбез.

Шуннан соң кәстрүлгә башлы суган һәм кишер (турамыйча) салабыз да тагын 20 минут кайнатабыз. Дәфнә яфрагы һәм түгәрәк борыч өстәп, утта тагын 10–15 минут тотабыз.

Итне кәстрүлдән чыгарып, сөягеннән аерабыз һәм турыйбыз. Яшелчәне, дәфнә яфрагын һәм борычны шулпадан җыеп алабыз.

Туралган итне койка ясау өчен уңайлы савытка салабыз, ваклап туралган сарымсак өстибез. Өстенә сөзелгән шулпа агызабыз. Суына төшкәч, суыткычка куябыз.

Телеңне йотарлык койка килеп чыгачак!

Укучы киңәше

Ялтыравын яратам

Бәйрәмгә әзерләнгәндә, иң элек савыт-сабага зур игътибар бирәм: рестораннардагыча матур итеп ялтырап торуын яратам. Ә чистарту серен миңа шунда эшләүче бер танышым өйрәтте.

Серe – дерес итеп чайкауда. 1,5 л суга 2 аш кашыгы тоз һәм 1 чәй кашыгы аш серкәсе салам. Аннары тәлинкә, чынаяк, бокалларны эремәдә чылатылган губка белән ышкыйм да киптерергә куям. Кипкәч, барысы да ялтырап тора!

Гөлфия НУРИСЛАМОВА. Казан

Исеңдә тот!

Аш-су сере

✓ Балыктан ләм исе килсә, шулпага тозлы кыяр яки тозлык өстәргә мөмкин.

✓ Ашка салынган дөге, изелеп, боткага әйләнмәсен өчен, ярманы башта майсыз табада кыздырып алырга кирәк.

✓ Балык ашына берничә кисәк алма салсаң, бик тәмле килеп чыгачак. Күзләрен һәм саңакларын алып ташлыйбыз, юкса шулпага әчкелтем тәм чыгачак.

Остаханә

КӘНФИТЛЕ ЧЫРШЫ

Кирәк: *яшел төстәге киҗе-мамык җеп, ябышкак тасма (скотч), катыргы, ПВА җилеме, тегү энәсе, чыршы өчен бизәкләр, балалар даруы дозаторы (яки энәсе алынган шприц).*

1. Катыргыны конус рәвешенә китереп, сүтелеп китмәсен өчен, скотч белән ябыштырабыз.

2. Энәгә җеп саплыйбыз. Шуның белән дозаторны яки шприцны тишәбез *(1 нче фото).*

3. Дозаторга җилем тутырабыз. Җепне җилемләп, конуска чорныйбыз *(2 нче фото).*

4. Конус җеп белән тулысынча каплангач, киптерү өчен алып куябыз. Шуннан соң катыргысын тартып чыгарабыз *(3 нче фото).*

5. Чыршыны мәрҗән кебек әйберләр белән бизибез дә очына шарчык урнаштырабыз *(4 нче фото).*

Чыршы эченә кәнфитләр тутырып куярга мөмкин. Яңа елга менә дигән сюрприз!

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында

Татарстан Республикасы Конституциясенең 75 статьясындагы 25 пункты һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 26 статьясындагы 3 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны үткәрү өчен бермандатлы сайлау округларының Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан тәкъдим ителгән схемасын расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Ф. Х. Мөхәммәтшин
Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2301-VI ДС

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасының график тасвирламасы



Округ номеры	Округ исеме, сайлаучылар саны
1.	Айдаров – 54059
2.	Копылов – 53323
3.	Кремль – 61151
4.	Яр буе – 53956
5.	Зареченский – 54144
6.	Декабристлар – 53791
7.	Ибраһимов – 53691
8.	Чуйков – 52952
9.	Ямашев – 54471
10.	Шаляпин – 60995
11.	Горки – 63103
12.	Габишев – 62814
13.	Дәрвишләр – 61741
14.	Пионер – 61717
15.	Азино – 61380
16.	Гвардия – 63684
17.	Комсомол – 57491
18.	Мәләкәс – 53285
19.	Үзәк – 56309
20.	Электротехника – 58087
21.	Вахитов – 58357
22.	Боровецкий – 53840
23.	Автозавод – 58664
24.	Студентлар – 56106
25.	Бызов – 61690
26.	Актүбә – 54525
27.	Девон – 52851
28.	Бигәш – 52911
29.	Әлмәт – 52915
30.	Сәйдәш – 62899
31.	Идел – 64014
32.	Бөгелмә – 62647
33.	Көньяк-Көнчыгыш – 57294
34.	Чистай – 57131
35.	Кама-Нократ – 56795
36.	Лениногорск – 60093
37.	Алабуга – 60824
38.	Зәй – 64718
39.	Азнакай – 61951
40.	Нурлат – 55581
41.	Буа – 66299
42.	Менделеевск – 58222
43.	Ык буе – 65865
44.	Алексеевск – 67673
45.	Апас – 51783
46.	Арча – 63964
47.	Кукмара – 62975
48.	Лаеш – 63698
49.	Питрәч – 54037
50.	Биектау – 55724

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
2023 елның 18 декабрендәге
2301-VI ДС номерлы
карарына кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын сайлауларны үткәрү өчен бермандатлы сайлау округлары схемасы

Бермандатлы сайлау округының номеры	Бермандатлы сайлау округының исеме	Бермандатлы сайлау округында сайлаучылар саны	Бермандатлы сайлау округының чикләре (һәрбер сайлау округына керә торган административ-территориаль берәмлекләр, яисә муниципаль берәмлекләр, яисә торак пунктлар исемлеге (әгәр сайлау округына административ-территориаль берәмлек, яисә муниципаль берәмлек, яисә торак пункт территориясенең бер өлеше керсә, схемада административ-территориаль берәмлек, яисә муниципаль берәмлек, яисә торак пункт территориясенең әлеге өлешенең чикләре күрсәтелергә тиеш)
1	**2**	**3**	**4**
1	Айдаров бермандатлы сайлау округы	54059	**Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Мәскәү районнарының бер өлеше түбәндәге чикләрдә:** Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан (М-7 «Волга») федераль трассасы Краснооктябрьск торак массивының Центральная урамы белән кисешкән ноктадан алып көнбатыш юнәлештә Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан (М-7 «Волга») федераль трассасы буйлап Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Зеленодольск муниципаль районы чиктәш чигенә кадәр, алга таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буйлап Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чигендә Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Совет районнары территорияләренең тоташу ноктасына кадәр, Крутушка торак массивын кертеп, алга таба Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Совет районнары чиктәш чиге буйлап Мәскәү – Екатеринбург тимер юлына кадәр, алга таба Мәскәү – Екатеринбург тимер юлы буйлап «Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводына кадәр, «Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы территориясе чиге буйлап, «Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы территориясен кертмичә, «5 нче бакча» С.П. Горбунов исемендәге КАҖБ күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтен кертмичә, Камчатка урамына кадәр, алга таба Камчатка урамы буйлап Пржевальский урамына кадәр, Пржевальский урамының так ягы буйлап Яңа Каравай урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба, Яңа Каравай урамы буенча 5 нче, 10 нчы йортларны кертмичә, Чапаев урамына кадәр, алга таба Чапаев урамының так ягы буйлап Чапаев урамы буенча 44 нче йорт, Челюскин урамы буенча 60а, 62, 68а йортлары буйлап, бу йортларны кертмичә, Северополюсная урамына кадәр, алга таба Северополюсная урамының так ягы буйлап Донецк урамына кадәр, алга таба Донецк урамы буйлап Айдаров урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Айдаров урамының так ягы буйлап Норлат урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Норлат урамының так ягы буйлап Максимов урамына кадәр, Челюскин урамы буенча 33/56 нчы, 35 нче йортларны һәм Беломорская урамы буенча 17 нче йортны кертмичә, алга таба Максимов урамының так ягы буйлап Челюскин урамы белән кисешкәнгә кадәр, Челюскин урамының так ягы буйлап ТЭЦ урамына кадәр, Побежимов урамы буенча 53, 55, 55а, 57, 57а йортларын кертмичә, Казан шәһәренең «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе территориясен кертеп, алга таба ТЭЦ урамының так ягы буйлап Копылов урамына кадәр, Копылов урамының так ягы буйлап Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Мәскәү районнары чиктәш чигендәге юлүткәргечкә кадәр, алга таба Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Мәскәү районнары чиктәш чиге буйлап Васильченко урамы, 6а йорты адресы буенча урнашкан автомобильгә ягулык салу станциясенә кадәр, автомобильгә ягулык салу станциясен кертмичә, алга таба Васильченко урамының җөп ягы буйлап Казан шәһәре Мәскәү һәм Киров районнары чикләре тоташкан урынга кадәр, алга таба Казан шәһәре Мәскәү һәм Киров районнары чиктәш чиге буйлап Казан шәһәре Мәскәү һәм Киров районнары һәм Зеленодольск муниципаль районы чикләре тоташкан урынга кадәр, алга таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиге буйлап Мәскәү – Владимир – Түбән Новгород – Казан (М-7 «Волга») федераль трассасы Краснооктябрьск торак массивының Центральная урамы белән кисешкән ноктага кадәр
2	Копылов бермандатлы сайлау округы	53323	**Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнарының бер өлеше түбәндәге чикләрдә:** Донецк урамы Северополюсная урамы белән кисешкән ноктадан алып Северополюсная урамының җөп ягы буйлап Челюскин урамы буенча 68а йортына кадәр, алга таба Челюскин урамы буенча 62 нче, 60а йортлары буйлап, аларны кертеп, алга таба, Чапаев урамы буенча 47а йортын кертмичә, Чапаев урамына кадәр, алга таба Чапаев урамының җөп ягы буйлап, Яңа Каравай урамы буенча 5 нче, 10 нчы йортларны кертеп, Пржевальский урамына кадәр, алга таба Пржевальский урамының җөп ягы буйлап Камчатка урамына кадәр, алга таба Камчатка урамы буйлап, «5 нче бакча» С.П. Горбунов исемендәге КАҖБ күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтен кертеп, «Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводына кадәр, алга таба «Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводы территориясе чиге буйлап, «Туполев» акционер җәмгыяте филиалы – С.П. Горбунов исемендәге Казан авиация заводын кертеп, Мәскәү – Екатеринбург тимер юлына кадәр, алга таба Казан шәһәре Авиатөзелеш һәм Яңа Савин районнары чиктәш чиге буйлап Короленко урамына кадәр, алга таба Короленко урамының так ягы буйлап Короленко урамы буенча 103 нче йортка кадәр, аны кертеп, алга таба Короленко урамы буенча 95, 97, 107 нче йортлар, Воровский урамы буенча 3а йорты буйлап, аларны кертмичә, Октябрь урамы буенча 36, 26, 28, 30, 32 нче йортлар буйлап, аларны кертеп, алга таба Октябрь урамының так ягы буйлап Гагарин урамы белән кисешкәнгә кадәр, Гагарин урамының җөп ягы буйлап Ибраһимов проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Гагарин урамы буенча 77 нче йортны, 77в йортындагы 1 нче корпусны, 77в йортындагы 2 нче корпусны, 79, 81 нче йортларны кертеп, алга таба Ибраһимов проспектының так ягы буйлап Казан шәһәре Авиатөзелеш районы чигендәге юлүткәргечкә кадәр, алга таба юлүткәргечтән алып Копылов урамының җөп ягы буйлап ТЭЦ урамына кадәр, алга таба ТЭЦ урамының җөп ягы буйлап Челюскин урамына кадәр, Челюскин урамының җөп ягы буйлап Социалистик урам белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан шәһәренең «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе территориясе чиге буйлап, Казан шәһәренең «12 нче шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе территориясен кертмичә, Челюскин урамына кадәр, алга таба Челюскин урамының җөп ягы буйлап Максимов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Побежимов урамы буенча 53, 55а, 57а, 57, 55 нче йортларны кертеп, Максимов урамының җөп ягы буйлап Норлат урамына кадәр, алга таба Норлат урамы буйлап Айдаров урамы белән кисешкәнгә кадәр, Айдаров урамының җөп ягы буйлап Донецк урамы белән кисешкәнгә кадәр, Донецк урамы буйлап Северополюсная урамы белән кисешкән ноктага кадәр
3	Кремль бермандатлы сайлау округы	61151	**Казан шәһәре Вахитов районы һәм Идел буе районының бер өлеше түбәндәге чикләрдә:** Кремль дамбасыннан алып Казан шәһәре Вахитов һәм Яңа Савин районнары чиктәш чиге буйлап Казан шәһәре Совет районы белән чиккә кадәр, алга таба Казан шәһәре Вахитов һәм Совет районнары чиктәш чиге буйлап тимер юл линиясе белән кисешкәнгә кадәр, алга таба тимер юл линиясе буйлап Универсиада проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Универсиада проспектының так ягы буйлап Халев урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Халев урамының җөп ягы буйлап Спартак урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Спартак урамының так ягы буйлап, Спартак урамы буенча 88б йортын кертеп, Газ урамы белән кисешкәнгә кадәр, Газ урамы буенча йортларны кертеп, алга таба Газ урамы буйлап Павлюхин урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Павлюхин урамының так ягы буйлап, 89, 87, 85 нче йортларны кертеп, Ипподром урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Ипподром урамының так ягы буйлап Спартак урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Спартак урамының так ягы буйлап Нурсолтан Назарбаев урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан шәһәре Вахитов һәм Идел буе районнары чиктәш чиге буйлап, Кабан күлен кисеп үтеп, Казан шәһәре Вахитов һәм Киров районнары чиктәш чигенә кадәр, алга таба Казан шәһәре Вахитов һәм Киров районнары чиктәш чиге буйлап Кремль дамбасына кадәр
4	Яр буе бермандатлы сайлау округы	53956	**Казан шәһәре Киров районының бер өлеше түбәндәге чикләрдә:** Югары Ослан муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урыннан алып төньяк юнәлештә Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чиктәш чиге буйлап Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнары территорияләре тоташкан ноктага кадәр, алга таба Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнары чиктәш чиге буйлап, «Аккош күле» урман-тау паркы һәм Окольная урамы, 10 нчы йорт адресы буенча «А.Ф. Агафонов исемендәге республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы (балалар клиникасы) территорияләрен кертеп, Восстание урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Восстание урамының җөп ягы буйлап Фрунзе урамы белән кисешкәнгә кадәр, Фрунзе урамының так ягы буйлап Коләхмәтов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба, Болотников урамын Болотников урамы буенча 13а йортына кадәр кисеп үтеп, Болотников урамы буенча 13а, 17а йортларын кертеп, Репин һәм Солнечная урамнары белән кисешкәнгә кадәр, Солнечная урамы буйлап, Солнечная урамы буенча торак йортларны кертмичә, «Казан дәүләт казна дары заводы» ФКП территориясе чигенә кадәр, алга таба «Казан дәүләт казна дары заводы» ФКП территориясе чиге буйлап, «Казан дәүләт казна дары заводы» ФКП территориясен кертеп, алга таба, Набережная урамы буенча йортларны кертеп, Набережная урамы буйлап һәм Идел елгасы акваториясе буйлап Казан шәһәре Киров һәм Вахитов районнары һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урынга кадәр, алга таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы чиктәш чиге буйлап Югары Ослан муниципаль районы, Зеленодольск муниципаль районы һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге чикләре тоташкан урынга кадәр
5	Зареченский бермандатлы сайлау округы	54144	**Казан шәһәре Киров һәм Мәскәү районнарының бер өлеше түбәндәге чикләрдә:** Окольная урамы, 10 нчы йорт адресы буенча «А.Ф. Агафонов исемендәге республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы (балалар клиникасы) территориясе чигеннән алып, «А.Ф. Агафонов исемендәге республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалын (балалар клиникасын) кертмичә, Окольная урамының так ягы буйлап Дары заводы зираты территориясенә кадәр, алга таба Дары заводы зираты территориясе буйлап, Дары заводы зираты территориясен кертеп, Сабан урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба, Сабан урамын кисеп үтеп, Сабан урамы буенча 1а йортын, Бакалейная урамы буенча 46а, 44а, 41 нче йортларны һәм Коләхмәтов урамы буенча 21 нче, 23 нче йортларны кертеп, Коләхмәтов һәм Серов урамнары кисешкәнгә кадәр, алга таба божра буйлап Серов урамының җөп ягы буйлап Ленская урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Ленская урамы буйлап 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамының так ягы буйлап Мулланур Вахитов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Мулланур Вахитов урамының җөп ягы буйлап Декабристлар урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Чистай урамының җөп ягы буйлап Бондаренко урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан шәһәре Мәскәү һәм Яңа Савин районнары чиктәш чиге буйлап Казан шәһәре Киров, Мәскәү һәм Яңа Савин районнары чикләре тоташкан урынга кадәр, алга таба Казан шәһәре Киров һәм Яңа Савин районнары чиктәш чиге буйлап Казан шәһәре Киров, Яңа Савин һәм Вахитов районнары чикләре кисешкән урынга кадәр, алга таба Казан шәһәре Вахитов һәм Киров районнары чиктәш чиге буйлап Киров дамбасына кадәр, алга таба Киров дамбасы буйлап һәм Идел елгасы акваториясе буйлап Казан шәһәре Киров, Вахитов районнары һәм Югары Ослан муниципаль районы чикләре тоташкан урынга кадәр, алга таба Казан шәһәре муниципаль берәмлеге һәм Югары Ослан муниципаль районы чиктәш чиге буйлап Боевая һәм Набережная урамнары кисешкәнгә кадәр, алга таба Набережная урамы буйлап, Набережная урамы буенча йортларны кертмичә, «Казан дәүләт казна дары заводы» ФКП территориясе чикләре буйлап, «Казан дәүләт казна дары заводы» ФКП территориясен кертмичә, Солнечная урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Солнечная урамы буйлап, Солнечная урамы буенча йортларны кертеп, Репин урамы белән кисешкәнгә кадәр, Репин урамы буенча торак йортларны, Лазарев урамы буенча 2 нче йортны кертеп, Болотников урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба, Болотников һәм Фрунзе урамнарын кисеп үтеп, Фрунзе һәм Коләхмәтов урамнары кисешкәнгә кадәр, алга таба Фрунзе урамының так ягы буйлап Восстания урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Восстания урамы буйлап Окольная урамы, 10 нчы йорт адресы буенча «А.Ф. Агафонов исемендәге республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы (балалар клиникасы) территориясе чигенә кадәр

6	Декабристлар бермандатлы сайлау округы	53791	**Казан шәһәре Мәскәү районының бер өлеше түбәндәге чикләрдә:** Окольная урамы, 10 нчы йорт адресы буенча «А.Ф. Агафонов исемендәге республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы (балалар клиникасы) территориясе чигеннән алып, «А.Ф. Агафонов исемендәге республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалын (балалар клиникасын) кертмичә, «4 нче бакча» коммерциягә карамаган бакчачылык ширкәте территориясе чиге буйлап «Химград» технополисы территориясенә кадәр, алга таба «Химград» технополисы территориясе чиге буйлап Васильченко урамына кадәр, алга таба Васильченко урамының так ягы буйлап, «Химград» технополисы сәнәгать территориясен кертеп, Васильченко урамы, 6а йорты адресы буенча автомобильгә ягулык салу станциясенә кадәр, алга таба автомобильгә ягулык салу станциясе территориясе чиге буйлап, автомобильгә ягулык салу станциясе территориясен кертеп, Мәскәү – Екатеринбург тимер юлына кадәр, алга таба Мәскәү – Екатеринбург тимер юлы линиясе буйлап, «Казан-2» транспорт-күчеп утыру узелы территориясен кертеп, Ибраһимов проспекты Воровский урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Ибраһимов проспектының җөп ягы буйлап Ибраһимов проспекты буенча 58 нче бинага кадәр, алга таба, Ибраһимов урамын кисеп үтеп, Черноморская урамы буйлап, Черноморская урамы буенча 3, 5, 9, 11 нче йортларны кертеп, Бондаренко урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Бондаренко урамының так ягы буйлап, Бондаренко урамы буенча 33 нче йортны кертеп, Чистай урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Чистай урамының так ягы буйлап Мулланур Вахитов урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Мулланур Вахитов урамының так ягы буйлап 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба 2 нче Көньяк-Көнбатыш урамының җөп ягы буйлап Ленская урамы белән кисешкәнгә кадәр, Ленская урамының җөп ягы буйлап Серов урамы белән кисешкәнгә кадәр, Коләхмәтов урамы буенча 23 нче, 21 нче йортларны кертмичә, Серов урамының так ягы буйлап Коләхмәтов һәм Серов урамнары киселешендәге боҗрага кадәр, алга таба, Бакалейная урамы буенча 41, 44а, 46а йортларын һәм Сабан урамы буенча 1 нче йортны кертмичә, Бакалейная урамы буйлап Дары заводы зираты территориясенә кадәр, алга таба Дары заводы зираты территориясе буйлап, Дары заводы зираты территориясен кертмичә, Восстания урамына кадәр, Восстания урамы буйлап Окольная урамы, 10 нчы йорт адресы буенча «А.Ф. Агафонов исемендәге республика клиник йогышлы авырулар хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе филиалы (балалар клиникасы) территориясе чигенә кадәр
7	Ибраһимов бермандатлы сайлау округы	53691	**Казан шәһәре Яңа Савин һәм Мәскәү районнарының бер өлеше түбәндәге чикләрдә:** Гагарин урамы Октябрь урамы белән кисешкән ноктадан алып Октябрь урамының җөп ягы буйлап Октябрь урамы буенча 16, 18, 20, 22, 24 нче йортлар буйлап, аларны кертеп, Октябрь урамы буенча 36 нчы йорт буйлап, аны кертмичә, Воровский урамы буенча 3а йорты һәм Короленко урамы буенча 107, 97, 95 нче йортлар буйлап, аларны кертеп, алга таба Короленко урамының җөп ягы буйлап Мәскәү – Екатеринбург тимер юлына кадәр, алга таба Мәскәү – Екатеринбург тимер юлы буйлап Фатыйх Әмирхан урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Фатыйх Әмирхан урамының так ягы буйлап Ямашев проспекты белән кисешкәнгә кадәр, Фатыйх Әмирхан урамы буенча 81, 83, 85 нче йортларны һәм Маршал Чуйков урамы буенча 27, 31, 33, 35, 35а, 37, 39 нчы йортларны кертмичә, алга таба Ямашев проспектының җөп ягы буйлап Бондаренко урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Бондаренко урамының так ягы буйлап Бондаренко урамы буенча 5, 7, 9 нчы йортлар, Короленко урамы буенча 23 нче йорт, Ибраһимов проспекты буенча 75, 73, 61а йортлары буйлап, аларны кертеп, алга таба Ибраһимов проспектының так ягы буйлап Гагарин урамы белән кисешкәнгә кадәр, Гагарин урамы буенча 81, 79, 77 нче йортларны, 77в йортындагы 1 нче корпусны, 77в йортындагы 2 нче корпусны кертмичә, алга таба Гагарин урамының так ягы буйлап Октябрь урамы белән кисешкән ноктага кадәр
8	Чуйков бермандатлы сайлау округы	52952	**Казан шәһәре Яңа Савин районының бер өлеше түбәндәге чикләрдә:** Фатыйх Әмирхан урамы Мәскәү – Екатеринбург тимер юлы линиясе белән кисешкән ноктадан алып Мәскәү – Екатеринбург тимер юлы линиясе буйлап Казан шәһәре Совет районы чиге белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Казан шәһәре Яңа Савин һәм Совет районнары чиктәш чиге буйлап Ямашев проспекты белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Ямашев проспектының җөп ягы буйлап Фатыйх Әмирхан урамы белән кисешкәнгә кадәр, алга таба Фатыйх Әмирхан урамының җөп ягы буйлап, Маршал Чуйков урамы буенча 27, 31, 33, 35, 35а, 37, 39 нчы йортларны, Фатыйх Әмирхан урамы буенча 81, 83, 85 нче йортларны кертеп, Мәскәү – Екатеринбург тимер юлы линиясе белән кисешкән ноктага кадәр
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ (843) 222-09-65, 222-09-70

КЕЧКЕНӘЛӘР ӨМЕТЕ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Бизәлгән чыршы, әфлисун исе, кайнар мунча, мичтә пешкән тәмле ризыклар. Инде бетеп барган яки бик кечкенә авылларда яшәүчеләр дә Яңа елны әнә шундый кәеф белән каршы алачак. Кайберләренең хәтта юлсызлыкка да эче пошмаячак. Арада өендә генә түгел, авылында бер кеше яшәгәннәре дә бар. Өметсезлеккә бирешми, ә Яңа ел төнендә ил-көнгә бәхет тели алар.

Тәкәрлек. Мамадыш

63 яшьлек Юрий Степанов – Мамадыш районындагы Тәкәрлек авылының бердәнбер кешесе. Аның ел әйләнәсендә авылдан беркая да чыгып киткәне юк. Карчанасына утырып, кирәк-яракка күрше авылга кибеткә бара. Урманга терәлеп торган өендә 23 ел инде ялгыз гомер кичерә. Аның авылда үзе генә яшәве турында моннан җиде ел элек язып чыккан идек. Хәзер дә берни үзгәрмәгән. Шалтыраткан саен Юрий бары бер сүзне генә әйтә: «Күңелсез түгел». Өендә моңаеп утырырга яратмый ул. Табигатьтә йөреп тә күңелен күтәрә белә. Сыерчыкларга оя ясый, күлгә килгән аккошларны күзәтә. Әле менә урмандагы бер чыршыны бизәп куйган. Шуның җем-җем утлары авылга бер ямь биреп тора, ди.

– Хәлләр Аллага шөкер. Кыш бабай килде инде безгә, чыршы куйды, – дип шаяртудан башлады сүзен Юрий. – Кем килсен инде монда? Юлларны ачучы юк. Техникам – карчана. Яңа елда табын кормыйм, үзем кунакка барырга җыенам.

Кызыл Чишмә. Бөгелмә

Бөгелмә районының Кызыл Чишмә авылында бүген 25ләп йортта 25ләп кеше яши. Калган нигезләргә кайтып-китеп йөриләр.

– Кичә кич авыл урамын әйләнгән идем. Күп йортларның ишекләре бикле, кышка яшәргә башка җиргә китәләр. Шундый моңсу, йөрәгем әрнеде. Урамнарда – асфальт, утлар якты. Су кергән, интернет бар. Су өчен түләмибез. Кечкенә генә авыл булса да, Әлмәт, Лениногорск, Бөгелмә шәһәрләренә якын. Тик нигәдер яшәргә килергә атлыгып тормыйлар шул. Эштән куркалармы, белмим. Дөрес, соңгы вакытта Әлмәттән килүче яшьләр бар. Медпункт, бакча, мәктәп булмагач, авылда каласылары килми, күрәсең, – ди фермер Зилә Гыйниятуллина. – Безгә дә балалар: «Әни, җитте инде, күп эшләдегез, ардыгыз, шәһәргә килергә вакыт», – диләр. Хуҗалыкта 70 баш сыер, 12 баш ат, сарыклар тотабыз. Сөт, каймак сатабыз – барысын да эшлибез. «Улым, мине үз аягым белән авылдан алып китә алмыйсыз. Шунда яшим, шунда гына йөрәгем тибә», – дим. Алай карт түгел әле без, илледә генә. Соңгы сулышымны шушы авылда алырга язсын.

Зилә ханымга, кибете булмаган, беткән авылда интегеп яшисез шунда, дип аптыраучылар да күп икән. Янәсе, бәхетсезләр. Кибетен ачар иде ул, тик аны тоту табышсыз. Ә менә машинасына утырып, каядыр сәүдә йортына барып кайтуның бернинди авырлыгы да юк.

– Без бик күңелле яшибез. Артыгы кирәкми. Кешеләр бәхетле булып яшәсен иде. Шәһәрдә бит эштән арып кайтып, күршедә кем яшәгәнен дә белмиләр. Гомерләре узганны да сизмиләр. Яз көне бөреләр ачылганны, яфраклар чыкканны күрмиләр. Көзен сары яфракларны кыштырдатып йөрмиләр. Ләззәт бит бу! – ди Зилә ханым.

Яңа ел төнендә ире Юныс белән урамга чыгып, Аллаһы Тәгаләгә һәм Путинга рәхмәт укыйлар икән. «Хөкүмәт программалары бар, субсидия бирәләр. Илбашыбыз алдында баш иям», – ди ул, шөкер итеп.

Алар авылда 500ләп чыршы, нарат, шомырт, юкә һәм башка агачлар утырткан. Өй каршындагы чыршыны бизәп, гирлянда элгәннәр инде. Үзе бер ямь.

Борчаклы Яз. Теләче

Соңгы 7 елда авылда нибары 3 кеше генә гомер итә. Анда 65 ел гомер кичерүче Людмила һәм Владимир Жуковларның хәлләрен дә белештек.

Авылда юлларны ачып торалар икән. Кирәк-яракка исә, такси чакырып, тиз генә кибеткә барып кайталар. Өйләренә газ кермәгән, чишмәгә суга йөриләр.

– Кеше калмады дип, Яңа елны үткәрмичә калмыйбыз. Ел саен чыршы бизибез. Ясалмасын түгел, чынны! Күңелдә тылсымга ышану һаман да бар әле. Людмила мичтә тәмле ризыклар әзерли. Бу көнне кызыбыз кунакка килә, – ди Владимир.

Владимир җәен каен себеркесе әзерли икән. Яңа ел кичендә мунча кереп, чабынып, көч җыялар. Аннан инде тәмле ризыклар белән сыйланып, телевизор карыйлар. Курантлар сукканда, бер-берсенә матур теләкләр телиләр. Тагын ни кирәк?!

Чәчкә. Әгерҗе

Әгерҗе районының Чәчкә авылында заманасында 130лап кеше яшәсә, хәзер нибары бер генә – 54 яшьлек тракторчы Фәнис Гыйльметдинов.

– Телевизор да, бар нәрсә дә бар. Күңелсезләнеп утырырга вакыт юк. Иртән торып мичкә ягам, аннан суга барам, кар көрим. Ярты көн шулай үтә. Аннан тагын өйне бераз җылытам, ашарга пешерәм. Менә шулай йокларга да вакыт җитә, – ди Фәнис. – Җәй көне тракторда эшлим, кышын ял итәм. Якын-тирәдә эш юк бит. Җәй көне чебешләр асрадым. Суыткычта ит бар. Тавыклар йомырка салыштыргалый. «Сельпо» машинасы күрше авылга товар илткәндә, юл уңаенда кирәкле әйберләрне чыгып алам. Зарланырга бер дә сәбәп юк. Улларым кайтса, чыршы карарга күрше Азево авылына кунакка барып кайтырмын, бәлкем.

Фәниснең авылда ялгыз яшәвенә 15 еллап инде. Авылны ташлап беркая да китәргә җыенмый. Әти-әни нигезе кадерле аның өчен.

– Мин китсәм, авыл бетте дигән сүз бит инде. Үземне «соңгы могикан» дип йөртәләр. Шуңа күрә авылны саклыйм, – ди ул.

Алмалы. Зәй

Алмалы авылында 29 йорт бар. Әмма дүрт кеше генә пропискада исәпләнә. Шуның икесе – авылда, икесе шәһәрдә яши.

– Кышын атна саен шимбә – якшәмбе юлларны ачарга тырышабыз. Егетләр кайтып йөри. «Дачный» авыл диярга була аны. Шәһәрдә эшләп арыгач, туган нигезләренә ял итәргә кайталар. Каникулда бала тавышлары да яңгырый. Яңа елны да каршылыйлар, – ди Югары Пәнәче авыл җирлеге башлыгы Мөнир Туктаров.

Аның әйтүенчә, авыл яши әле. Бары көз, яз айларында юлсызлык проблемасы гына бар. 2030 елга кадәр республика программасы белән газ кертү көтелә. Авылда – һәркемнең үз коесы. Өч еллык программада үзәкләштерелгән су кертү планлаштырыла.

Тархан. Азнакай

Азнакай районы Тархан авылында искесен, яңасын санаганда, 50ләп йорт бар. 11 йортта барлыгы 21 кеше теркәлгән. Җәй көне 50ләп кеше яшәсә дә, кышны җиде йортта гына чыгалар.

– Авылда чыршыны ишегалдына куябыз. Әле менә күрше шалтыратып, өйләрне бизәү буенча бәйге уздырылачагын әйтте. Без Илбәк җирлегенә карыйбыз. Анда ел саен чыршы бизәп, безне дә бәйрәмгә чакыралар. Бик күңелле үтә, – ди фермер Миләүшә Әмирова.

Сәрия МИФТАХОВА әзерләде

Чулпан
ГАРИФУЛЛИНА

ҖЫРЛАНМАГАН ҖЫР,

ЯКИ БАЛАЛАР РЕПЕРТУАРЫ НИК САЙ?

Бар да кебек, барлый башласаң, юк та. Сүзебез – балалар өчен иҗат ителгән җырлар турында. Килешерсезме-юкмы: хәзер сәхнә тоткан балалар авызыннан үз яшьләренә туры килердәй җырлар бик сирәк ишетелә. Әйтик, яралы, җавапсыз мәхәббәт хакында җырларга тырышалар. Монда бала-чаганың гаебе юк та кебек. Оясында ни күрсә, дигәндәй...

Балалар өчен яңа җырлар ник юк? Булып та, ни өчен алар популяр түгел? Репертуар сайлаганда, балалар, педагоглар һәм ата-аналар нәрсәгә игътибар итә? «ВТ» хәбәрчесе шушы сорауларга җавап табарга тырышты.

shayantv.ru / фото бизәү өчен бирелә

Әле дә ярый электән калган моңлы мирасыбыз бай. Юкса балалар репертуар нәрсәдән торыр иде?

Зурлар кызыксынмагач...

– Чынлап та, моннан дистә ел элек нинди җырларны җырлаган булсак, әле дә шуларны җырлыйбыз икән. «Чыршы, чыршы»ны, Гөлшат апа Зәйнәшеваның «Җырлыйм әнием турында» җырын, мәсәлән. Алар инде күптән классика, онытылмыйлар. Ә яңа балалар җырлары, чынлап та, хәтергә бик кереп калмый... – ди балалар язучысы, журналист Алмаз Гыймадиев.

Бу хәлнең сәбәпләрен дә атады:

– Балалар өлкәсенә бәйле бөтен нәрсә – әдәбиятмы, музыкамы – икенче планда. Никтер бездә беренче урында һәрвакыт – зурларныкы. Бу бик кызганыч, әмма бу шулай.

Бу җәһәттән язучылар: «Балалар өчен язу авыр, балаларның психологиясен белергә кирәк», – дип әйтеп кул селтәгәнне башкалар да алынырга атлыгып тормыйдыр, билгеле. Шулкадәр авыр өлкә булгач... Югыйсә зурлар өчен хитлар көн саен туа.

– Зурлар җырлый торган шәп җырлар гел чыгып тора. Ә менә: «Быел балалар өчен нинди шәп җыр язылды?» – дип сорасалар, берәү дә берни әйтә алмастыр, – ди Алмаз Гыймадиев.

Әңгәмәдәшебез, мәсьәләне хәл итүгә бер нәрсә булышыр иде, ди. Ул да булса – балалар өчен фильмнар.

– Русларда бит күп кенә шәп җырларны балалар өчен фильмнарда файдаланалар. Шуннан ишетеп, отып та калалар. Мәсәлән, «Приключение Электроника» фильмындагы җырларны гына алыйк. Ә бездә балалар өчен фильмнары да юк әле. Менә ничек барысы да бер-берсенә бәйләнеп бара бит, – диде Алмаз Гыймадиев. – Татар балалары шуңа да чит җырларны көйләп йөри, ә сәхнәдән зурлар җырын җырлый.

Җырлары бар, ә җырчысы?

Мультиинструменталист, музыкант, мөгаллим Ильяс Фәрхуллин балаларның эстрада җырларына, аерым алганда, мәхәббәт темасына тартылуы аларның иртә җитлегүенә бәйле дип саный.

– Иртә җитлегү дигәндә нәрсәне аңлыйбыз? Аларның хәзер бар нәрсәсе бар, алар җәмгыятькә бик тиз җайлаша белә. Шул җайлашу нәтиҗәсендә бик иртә гашыйк та булалар, бик иртә аерылышалар да. Балалар өчен бик күп нәрсәгә ишекләр ачык: телефон, интернет, башкасы, дисеңме. Әйтик, минем беренче телефоным 14 яшьтә генә барлыкка килгән иде. Анысы да – шалтырату өчен генә яраклысы. Балалар хәзер бөтен нәрсәне күреп үсә. Балалар өчен җырлар юк дип әйтү дөрес булмас. Алар языла. Махсус конкурслар да бар бит. Җырлар бар. Аны кызыксынып җырлаучы балалар гына юк дәрәҗәсендә, – ди Ильяс.

Кызыксыну димәктән. Әңгәмәдәш, монда ал хыялларга бирелеп булмас, дип уйлый.

– Бу заманда андый җырларга кызыксыну уятып буламы икән? Белмим. Берәр балалар җыры ялгыш кына хитка әверелсә, бәлки, аз булса да кызыксыну туар иде. Берничә ел элек «Синий трактор» дигән җырны бөтен дөнья җырлады. Шуның кебек җыр кирәк, – ди ул.

Халык җырларына да «почет»

Казанда яшәүче Зөлфирә Җаппарова – өч бала анасы. Кызлары Мәрьямне күпләр «Шаян ТВ» каналы аша да танып белергә мөмкин. Кызчык җыр сәнгатенә гашыйк, Казан шәһәренең 1 нче музыка мәктәбендәге «Сөембикә» вокаль ансамблендә йөри. Репертуарны алар ничек барлый икән? Балалар җырына кытлык сизәләрме?

Зөлфирә ханым әйтүенчә, хәзер, киресенчә, авторлар белән эшләү, балалар репертуарын баету өчен шактый эш башкарыла.

– Балалар өчен җырлар юк дип өздереп әйтеп булмый. Текст белән эшләргә кирәк. Халык җырлары арасында да балалар башкара алырдайлары шактый. Кызым йөргән ансамбльдә балалар классикага өстенлек бирә. Монда мәхәббәт турында гына җырлар юк. Туган як, табигать, туган җир, Казанга бәйле җырлар, мәсәлән. Мәрьям халык җырларын яратып башкара, шулай ук классикларыбыз әсәрләрен. «Илкәем», «Иртәнге нур», «Идел буе каеннары», махсус «Балачак җыры» проекты өчен язылган «Әнием – газиз кешем» җыры... Хәзер кызым Мәрьям «Җидегән чишмә»не өйрәнә. Хәер, аны да балалар җыры дип әйтеп булмыйдыр. Әмма укытучысы: «Тавышына һәм башкара алу мөмкинлегенә туры килә», – диде. «Ни өчен балалар мәхәббәт турында үзләре дә аңлап бетермәгән җырлар җырлый?» – дигән сорауга әйләнеп кайтсак, җыр буларак аларның безнең халыкта популяр булуы роль уйный дип саныйм. Балалар өчен дип язылган җырлар популярлашып китә алмый, ә зурларныкы гел колак очында булгач, танылган. Балаларга да кеше телендә булганны башкару кызык. Әмма аларның яшенә туры килмәве хак, – ди Зөлфирә Җаппарова.

Кызы Мәрьям исә, үсмерләр өчен җырлар күбрәк булсын иде, дип тели.

– Балалар бакчасына йөрүче нәниләр өчен җырлар күп. Башкару өчен алар бик җиңел, бер октава эчендә, күңелле җырлар ул. Әмма үсмерлек яшенә җиткән балаларга инде музыкаль яктан тавыш мөмкинлеген үстерердәй, сүзләре дә туры килгән репертуар сайлау авыррак, – ди ул.

Соңгы сүз урынына

...Кулга каләм алырга этәргән сәбәпне дә атап үтсәк, дөрес булыр. Бер җырчының концертында ир баланың сәхнәдән «җавапсыз мәхәббәт», «бергә була алмадык» дип моңлануы гаҗәпкә калдырган иде «ВТ» хәбәрчесен. 10–14 яшь арасында шулкадәр хәсрәтле, яралы мәхәббәт буламы икән ул? Баланың үзе кичермәгән хис турында җырлавы ышандырмый да, ихлас та түгел.

Конкурсларда бәяләнгән, урын алган җырлар җыентык итеп басылгандыр, балалар бакчасында, мәктәпләрдә дәресләр кысасында башкарылалардыр, анысына шик юк. Әмма ул җырлар зур сәхнәләрдә ишетеләме? Эфирда, радиода яңгырыймы? Әллә без генә ишетмибезме? Соңгысы булса – бик хәерле. Танылу алганмы алар? 10–15 ел узгач, алар белән ни булыр?

Әлбәттә, балаларны хәзер «Салют сиңа, Муса Җәлил!», «Зәңгәр күл» ише җырлар белән кызыктырып булмый. Туган як, әти-әни, туган тел кебек үлмәс темалар бар һәм булыр, әмма замана баласының кызыксынулары бүтән. Халыкчан да булсын, кызык та, заманча да. Хәзерге балалар җырына әнә шундый таләпләр куела булса кирәк. Таләпләр үтәлерме?

«КИЛӘСЕ КАЙТКАНДА, ӘНИ...»

Соңгы очрашулары июнь аенда була аларның. Айрат кечкенә кызчыгы белән хатынын бала тудыру йортыннан алып чыгарга кайта. Нибары бер көнгә. Үзенә тиешле ун көнен дә ял итмичә, кабат егетләр янына ашкына. Бер атна вакыт узуга, 32 яшьлек капитан Айрат Байковның үлеме турында хәбәр килә. Аның 28 яшьлек хатыны 13 көнлек һәм 4 яшьлек ике кызы белән тол кала.

Белешмә

Айрат БАЙКОВ 1990 елның 6 ноябрендә Мамадыш шәһәрендә туа. 2005 елда 8 нче сыйныфтан соң Казан Суворов училищесына укырга керә. 2008 елда, уку йортын тәмамлап, Айрат башта Казан югары артиллерия команда училищесында, аннары Санкт-Петербургтагы хәрби академиядә белем ала. 2013 елда Сахалинда хезмәт итә башлый. 2018 елда Сүриягә командировкага бара, ә 2022 елның февралендә махсус хәрби операциягә җибәрелә. Капитан Айрат Байков 2023 елның 2 июлендә һәлак була. Мамадышта ул укыган 2 нче лицейда батыр егеткә истәлек тактасы куелды.

Әлфия Байкованың шәхси архивыннан

Айратның хатыны – тол, ике кечкенә кызы ятим калды.

Ана йөрәге

Авыр чакларында зур хәсрәтне бүлешкән һәр кешегә рәхмәт укый Байковлар.

– Кемнең кем икәнен шул чакта беләсең икән. Туган яктан күп кеше килде. Без инде күптән Казанда яшәсәк тә, район хакимияте ярдәменнән ташламады. Иремнең якташлары, Шадче авылы игътибарсыз калдырмады, – ди Әлфия апа. – Вакыт – дәва, дисәләр дә, дөрес түгел. Батыр йөрәкле ул үстерүемә горурланам. Әнә шул бераз тынычландыра мине. Аның медаль-орденнары гына да күпме! Вакытында мактый да белмәдем бит!

Мамадышта 8 нче сыйныфны тәмамлагач, Айрат Казанга Суворов училищесына укырга керә.

– Сабыйны чыгарып җибәрү җиңел булмады. Әмма аның хакына барысына әзер идек. Улым кая бара – без дә шунда булдык. Мамадышта яшәгәндә, Казан юлын таптадык, улым Санкт-Петербургта хәрби академиядә белем алганда, анда барып йөрдек. Сахалинга җибәргәч, анда да бардым. Махсус хәрби операция башланганда, аның инде пенсиягә чыгу яше җитеп килә иде. Айрат исә ул хакта уйлап та карамады. Гел бер сүзне кабатлады: «Без бармасак, тагын кем барыр?!»

Әлфия апа бик өзгәләнә. Сүз саен тиз-тиз күз яшьләрен сөртүен, миңа сиздермәскә тырышып борынын тартуын күреп, күңел тула. Тугыз ай карынында йөрткән, кадерләп үстергән, инде хәзер гаиләсенә сөенеп яшәгән чакта улыңны югалт та елама, имеш! Ничек еламасын инде, ана бит ул!

– Бала хәсрәтеннән дә зуррак кайгы юк икән. Моны сүзләр белән генә аңлатып булмый. 32 яшьлек имәндәй балам салкын җир астына кереп ятсын инде! Сагынуга, йөрәк тулы сагышка түзәрлек түгел. Бер ана да мин кичергәнне кичермәсен. Сабыйлар әтиләренә ошаган. Балаларын югалткан әти-әнигә сабырлык бирсен Раббым! Башка хәсрәтләр күрергә язмасын.

Ата йөрәге

Айратның әтисе дә бу югалтуны авыр кичерә.

– Мин – Актаныш кызы. Керәшен егетенә кияүгә чыгасымны белгәч, әткәй-әнкәй башта бик борчылды. Әмма бәхетемә каршы төшмәделәр. Ирем белән бик аңлашып яшибез. Бала хәсрәте аның иң яхшы ир, иң зур йөрәкле әти, сабыр кеше икәнен тагын бер мәртәбә күрсәтте. Кычкырып елый да алмый бит әле алар. Бик авыр булды аңа! Айратның җәсәден, Ульяновскига барып, үзе каршы алды. Ничекләр түзгәндер йөрәге? – дип сөйли Әлфия апа. – Ирем көн саен диярлек улым янына барып йөрде. Кабере янына килгән саен, бер күбәләк килеп куна икән. Хәзрәт белән сөйләшкәннән соң, бераз тынычланып калды. Әле күптән түгел улыбызның һәлак булган урынын күреп кайтты. Бер ялгызы юлга чыкты да китте. Әле ярый яхшы кешеләр очраган. Юл уңае булмаса да, улым хезмәт иткән җиргә илткәннәр.

Айратның үзен дә, матур күңелле, кешелекле иде, дип искә алалар. Намазларын калдырмый. Исән-имин кайтасына өмет белән яши. Гел сөйләшеп торалар. Нинди генә хәл булса да, якыннары белән элемтәгә чыгарга тырыша, юату сүзләре таба. Ул һәрвакыт, мин анда кирәк, иптәшләрем көтә, егетләргә терәк булам, дип кабатлый.

Офицер хатыны

Казан кызы Алия белән Айрат биш ел элек гаилә корып җибәрә. Бик ярату шып өйләнешә алар. Алия иреннән биш яшькә кече булса да, акыл белән тормыш итә. «Минем Айратым», – дип кенә тора. Әлфия апа киленен, чын офицер хатыны, дип атый. Ире кайда хезмәт итсә, шунда бара ул.

– Улыбыз махсус операциягә киткәч, киленебез анда да барып кайтты. Мин аңа бик рәхмәтле. Шуннан кайткач, икенче кызлары туды. Айратым баласын күрергә кайткач, зур итеп аш уздырдык. Исем куштырдык. Ике балага да корбан чалдырдык, – дип сөйли Әлфия апа. – Алиягә бик авыр икәнен аңлыйм. Үз хәсрәтен үзе генә беләдер. Кулдан килгәнчә ярдәм итәргә тырышабыз. Кодагыйларым белән яши. Оныкларны карашырга күбрәк алар булыша. Улымның дәвамчыларын үстергәне, изге күңеле, баламны бәхетле итә иткәне өчен Алиямә мең рәхмәт.

Якыннары Айратны төшләрендә матур итеп күрә. Улларының рухы шаттыр, дип юаналар. Ә күңелләрендәге сагыш беркая да китми, кимеми дә. Әлфия апа әйтмешли, гомер буена җитәрлек йөрәк ярасы. Бөтенләйгә киткәнен белсә дә, әни күңеле барыбер көтә. Теге вакыттагы кебек. Соңгы киткәндә, әнисе биргән җиләк кайнатмасын самолетка алып керергә рөхсәт итмиләр. Айрат әйләрәнә шалтырата: «Киләсе кайтканда алып китәрмен, әни. Киләсе кайтканда...»

Гөлгенә ШИҺАПОВА

Булышасы иде...

19 декабрь көнне Биектау районының Олы Кавал авылында яшәүче Садыйковларның йорты янып, көлгә әйләнгән. Йорт хуҗасы Илдар хатыны Фирая белән биш бала үстерә. Кышкы салкында 6 кешелек гаилә бернәрсәсез урамда кала.

Бөтен авылдашлары бу гаиләгә булышырга алына. Иң элек алар авыл буйлап акча җыя, аннары бу хәлне интернетка чыгара. Ике көн эчендә 200 мең сум акча җыйганнар да инде. Әмма йорт җиткерер өчен бу гына җитми, әлбәттә.

– Ут капкан чакта мин мунчада идем. «Әти, янабыз!» – дип, улым йөгереп килде. Башта ышанмадым. Йөгереп чыгып карасам, аш бүлмәсе яна башлаган иде. Каушап та калдык инде. Нишләргә белмәдем, – ди Илдар. – Ут электр чыбыклары тоташкан җирдән чыккан. Янарбыз дип кем уйлаган инде аны. Бик читен. Тыныч кына гомер иткәндә, гаиләбезгә мондый хәсрәт килер дип уйламаган идек. Безгә ярдәм иткән һәркемгә рәхмәт.

Олы Кавал җирлеге башлыгы Фәнил Гыймадиев белән дә элемтәгә кердек. Әлеге гаиләгә ничек тә булышасы иде, ди ул.

– Садыйковларның өйләреннән документларын һәм бераз кирәкяракларын алып чыга алдылар. Бездә кеше бик бердәм. Шул ук минутта җыелышып, ярдәм итәргә тотындылар. Әлегә Садыйковлар үз өйләреннән ерак түгел Фираяның әниләрендә яшәп торалар. Язга чыккач, йорт җиткермәкчеләр, – ди җирлек башлыгы.

Ут тиз таралган. Янгын сүндерүчеләр килгәндә каралты-кура янып бетәргә өлгерә. Авылдашлары, әле ярый янгын төнлә чыкмаган, дип сөенә. Интернетка хәбәрне туганнары Рәсим чыгара.

– Бераз ярдәм булмасмы дигән идем. Алар бит бернәрсәсез калды. Ярый, суыткычны алып чыга алдык. 50 мең булса да акча җыеп булмасмы дигән идем, шөкер, 200 меңнән артты инде. Мин барысын да хуҗаларга тапшырачакмын, – ди ул.

Илдар абыйның бертуганы Фәридә Кәлимуллина да бу гаилә өчен акча җыя башлаган. Аны бик ярдәмчел, авылдашлары өчен янып-көеп йөрүче, ышанычлы кеше, дидиләр.

– Әлеге гаиләнең үз карталары юк. Шуңа күрә изге күңелле авылдашларыбыз җыя. Кеше хәсрәтенә битараф булмаган һәркемгә рәхмәттән башка сүз юк. Үз игелегегез меңе белән әйләнеп кайтсын, – ди җирлек башлыгы.

Садыйковларга ярдәм итәргә теләүчеләр Фәридә Кәлимуллина исемендәге Саклык банкы картасына акча күчерә ала. Карта **89503138525** телефонына беркетелгән.

РӘНИФ ШӘРИПОВ:

«ИШЕКЛӘРНЕ ТИБЕП АЧА БЕЛМИМ»

«Иҗат эше ыгы-зыгыны яратмый», – ди ул. Әллә шуңа, ил-гавамнан читтәрәк калып, бар булмышын иҗатка багышлап яши. Сүзебез – шагыйрь Рәниф ШӘРИПОВ турында. Аның белән иҗат хәлләре, әдәбият проблемалары турында сөйләштек.



:: Рәниф абый, сүзне хәл-әхвәл белешүдән башлыйк. Нихәлләрегез бар?

– Хәлләр начар түгел, Аллага шөкер!

:: Фәнис Яруллинның көндәлекләре аша иртәсенең бик иртә башлануын, бик күп кешеләр кабул итүен белдек. Сезнең көнегез ничек башлана, ничек үтә?

– Фәнис абый белән чагыштырганда, мин күпкә ялкаурак шул. Иртә тормыйм. Күптомлыклар чыгарырлык язганым юк, гәрчә аз язмадым кебек. 25ләп поэма гына бар. Сан өчен түгел, бик тә абруйлы әдипләребездән шактый югары бәя алган әсәрләр. Кемнеңдер чагыштырганы бар, имеш, бер поэма бер роман кебек дип. Яшьрәк вакытта көнем сәгатьләргә, мәсәлән, чит телләрне өйрәнү, уку, тарих, әдәбият, физкультура... кебек «дәрес»ләргә бүленгән иде. Язу эшен исемлеккә кертеп булмый, билгеле. Анысы сәгатьләргә бүленми, үз тормышы белән яши. Хәзер инде режим буенча яшәмим, «пенсиягә чыктым».

:: Сезне, холыкларыгыз капма-каршы булса да, Фәнис Яруллин белән чагыштыралар да бугай әле.

– Андый чагыштыруларны бөтенләй яратмыйм. Фәнис абый янында кунакта булгаладым. Без – икебез ике төрле кеше. Үземнең ялкаулыгым турында әйттем инде. Аннан соң, мин сорарга яратмыйм, бөтенләй яратмыйм. Бу – минем өчен үз-үзеңне кимсетү, түбән төшерү.

Детдом безне еламаска,
Елап сорамаска өйрәтте...

:: Әниегезнең нинди нәсыйхәте язмышыгызда хәлиткеч роль уйнады?

– Әнием нәсыйхәтләре булдымы, юкмы – хәтерләмим. Үләр алдыннан чакырып алып: «Улым, мин үләм. Син курыкма, сине хөкүмәт ташламас...» – диде. Сүзгә-сүз. Шул булды нәсыйхәт.

:: Татар әдәбиятында ятимлек, балалар йортында тәрбияләнү темасы элек-электән булган, хәзер дә бар (соңгы елларда Зөлфәт Хәким, Айгиз Баймөхәммәтов һ.б.лар язды). Бу теманы эчтән белсәгез дә, язмыйсыз. Сәбәбе нәрсәдә икән?

– Әлеге авторларны ишетеп беләм, ләкин укыганым юк. Әйе, бу теманы мин бик яхшы эчтән беләм. Язмыйсыз дип әйтү дөрес түгел. Язгалыйм. «Качу», «Алмагачлар сагышы». Ләкин, бу темага кагылганда, мин, һәрвакыт дип әйтергә була, мәхәббәт белән язам. Бәлки шуңадыр да, ул әсәрләр җиңелчә генә, «еламыйча» гына укыла, халык телендә йөрми.

:: Фәнис абыйның Нурсәясе булса, сезнең терәк-таянычыгыз, илһамчыгыз Дамирә апа бар. Аның белән соң кавышканга үкенмисезме?

– Әйе, без соңрак кавыштык. Инде ун елдан артык бергә. Шөкер итеп яшибез.

:: Хатыныгызга яратам дип әйткәнегез бармы? Көндәлектә аңа ничек эндәшәсез?

– Яратам, дип әйтешкән чаклар да булды. Гомумән, роман язарга була. Кәеф әйбәт чакта, матурым, дип дәшәм, кәеф булмаганда, Дамирә инде...

:: Сез социаль челтәрләрдә бик актив. Шигырьләрегезне күбесенчә кемнәр укый? Гомумән, шигърият бүген ни дәрәҗәдә популяр?

– Шигырь укучылар да, язучылар да күп. Интернет тулы. Монда инде сыйфат, зәвык кебек төшенчәләр калкып чыга. Хәер, күзәткәлим: һәркемнең үз укучысы, язучысы бар. Интернетта – тулы демократия. Мин шуңа бик сөенгәм: укучы барысын да аңлый, сизә, тоемлый. Бер яшь ханымның минем шигырьгә җавабы хәтергә уелып калды: «Кызганыч шигырь дә түгел, ләкин нигәдер елыйсы килә...» Бик уйландырды бу сүзләр. Ул бит могҗиза белән очрашкан кебек язган бу бәяне. Шигъриятнең сере дә, бәлки, шулдыр. Тагын бер сүз әйтәсем килә: интернетта Чаллыдан Айрат Суфиянов исемле бик шәп шагыйрь еш күренә. Гениальный дип әйтсәм дә, артык булмас. Җанытәне белән чын шагыйрь. Күп яза, әйбәт яза. Менә дигән шигърият үрнәкләре күрсәтә. «Нигә әле бу?» – димәгез, бәлки, аңа да игътибар артыр, күрерләр, булышырлар... Ул – телебез, халкыбыз байлыгы.

:: Рәниф абый, сезнең барлыгы ничә китабыгыз чыкты? Бөтен иҗатыгызны туплап чыгару өчен ничә томлык кирәк булыр иде?

– Барлыгы сигез китабым чыкты, шуларның дүртесе каты тышлы, кем әйтмешли. Барлык иҗатны туплау кирәк түгелдер, бәлки. Шулай да, сыйфатлы гына итеп ике томлык әзерләргә булыр иде. Китап кибетләрендәге киштәләргә, андагы сатылмыйча яткан күптомлык әсәрләргә күзем төшә дә, бер томлык та җитәр иде, дип уйлап куям. Бу – бары тик уйлар гына.

> Өмет юк, дип әйтергә була. Соңгы китабымны бик зур кыенлыклар аша чыгардык. Кайвакыт, йөгерә-йөгерә китап бастырыр өчен, өстән бер генә сүз дә җитә икән. Барысы да табыла...

Хәзер ул якка борылып та карыйсы килми. Шигырь дә язган идем әле, «Кем кулында безнең язмышлар...» дип. Чөнки, «социаль әһәмияте юк» дигән мөһер сугып, минем китапны бөтенләй юк итәргә маташканнар иде. Шулай булыр да иде, ярый әле, бер таныш «олы абзый»: «Хәлең ничек?» – дип сорады. Мин җавап бирдем... Үзем турында, күргәннәрем турында кечкенә-кечкенә истәлекләр язган идем, интернетка куеп та бардым, бер китаплык җыелды. Тик шикләнәм, «социаль әһәмияте» юктыр. Кемнәндер ярдәм сорыйсым килми.

:: Иҗатыгыз вакыт-вакыт бик усал, әмма үзегез усал түгел бугай. Юкса фәлән түрәләрнең ишекләрен тибеп ачуыгыз турында бер дә ишетелми. Китабыгыз аз тираж белән чыкты, урамга чыгып йөреп булмый торган йортта өске катта яшисез. Саный китсәң, күп инде...

– Иҗатым үземә бер дә усал түгел шикелле. Һаман шулай диләр. Әллә чынлап та шулай инде?! Бу дөньяның, бу тормышның ямьсез, гаделсез якларын күрсәм, шунда ук ачуым чыга. Ябык ишекләрне тибеп ача белмим, борылам да китеп барам.

:: Шәхесләргә багышланган поэмаларыгыз бар. Алар арасында иң катлаулысы дип кайсын әйтер идегез?

– Таһир Якупов турында «Куылган моң», Вафирә Гыйззәтуллина турында «Вафирә», Фәүзия Бәйрәмова турында «Фәүзия» дигән поэмаларым бар. Барысы да катлаулы. Бераз гына тәнкыйть тә булды. Бәхәсләшмим, бер-ике сүз генә әйтәм. Поэма ул – документаль язма түгел, ә хисләр дөньясы, шигъри әсәр. Теге чоры кермәгән, бу вакыйга сурәтләнмәгән, дип тәнкыйтьләү урынсыз. Икенчедән, ничек кенә ачы булса да, дөреслекне язарга куркып узсаң, каян килсен әсәргә хисләр? Тәнкыйтьтә хикмәт бар, аңа да колак салам, ләкин, янүд мәзәгендәге кебек, алар да хаклы, мин дә хаклы.

:: Хәзерге заман турында поэма язылса, ул ничек аталыр иде?

– Хәзерге заман турында поэма язып булмас иде. Физиклар һәм лириклар арасындагы бәхәстә физиклар җиңде, «0» һәм «1» калып бара, ягъни информатиканың нигезе, «бар» һәм «юк», бөтен дөнья шул саннарга кереп югалып бара, ясалма интеллект та – шул цифрлар дөньясы. Бәлки, ялгышамдыр, без хисләр табигатен әле һаман да аңлыйаңлата алмыйбыз. Ә ясалма акылны үзебез белмәгән нәрсәгә өйрәтергә маташабыз. Компьютерлар эчендә хисләргә урын юк.

:: Ил-көндәге вазгыять иҗатка ни дәрәҗәдә тәэсир итә?

– Тәэсире шул гына: күп уйланырга туры килә.

:: Соңгы елларда иҗади конкурслар, грантлар барлыкка килде. Әдәби бәйгеләрдә катнашканыгыз бармы? Юк икәнен белсәм дә, сорыйм инде: бәлки, фикерегез үзгәргәндер? Анда җиңүчеләрнең иҗатларын күзәтеп барасызмы? Андый конкурслар файдагамы?

– Иҗат эше ыгы-зыгыны яратмый дигән сүзне ишетмәгән кеше бармы икән? Үземнең катнашканым юк. Бәйгеләрнең файдасы бар инде ул. Ләкин иҗат эшендә... Белмим. Иҗат бәйгесе гасырлар буена сузылып бара бит ул.

:: Тагын бер ел тәмамланып килә. Сезнең өчен ул нинди ел булды? Киләсе елны нинди өметләр белән каршы аласыз?

– Узган ел гадәти ел булды, дип әйтер идем, алай түгел шул. Киләсе ел гадәти ел булсын иде дигән өметләр белән яшибез...

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

ФИРДҮС ГЫЙМАЛТДИНОВ

ӨЯНӘК

(хикәя)

< Дәвамы. Башы 8 декабрь санында

Алты тулу белән, ул урыныннан ашыкмый гына торды, ике кулыннан ике җиңсәне салып, пөхтә генә итеп төреп, өстәл тартмасына яшерде. Аннан соң урындык аркасына эленгән пинҗәген киде. Күкрәк кесәсеннән кечкенә генә тарак чыгарып, чәчләрен рәтләгән итенде дә, таушалудан музей экспонатына охшап калган портфелен эләктереп, ишеккә ашыкты. Их, шунда чыгып барган шәпкә ишек катында контора нәчәлнегe белән очрашсалар! Икесе дә тәртип буенча, кичке алтыда кайтырга чыгып тегесе дә күрер иде дә бит... Юк, нәчәлнекләре күптән инде каядыр китеп олаккан, машинасы әбәттән бирле күренми. Яшьләр...

Миңнулланың бердәнбер җан дусты Сәлим бар. Бүген ул эштән соң аның белән күрешергә сүз куешты. Сәлим, бу хәбәрне ишеткәч тә, яман шатланды, хатынын ахирәтенә кунакка җибәреп үк куясын әйтте. Кунак килгән төшкә ул бер табак ит пешереп куйган иде, аның янәшәсенә урталай киселгән бәрәңге. Миңнулланы элек һичшиксез ымсындырырга тиешле башлы суган да ак сыртын ялтыратып ята. Янәшәсендә – зур телемләп киселгән кара икмәк...

Күрешеп, портфельдән бер шешә коньяк чыгарганнан соң да, хәтта табынга утырып иллешәрне кәккәч тә Миңнулланың кәефе һич ачылып китмәгәнлеккә Сәлим нык гаҗәпләнде.

– Дустым, ни булды сиңа?! Йөзең качкан. Өйдә берәр кайгы бармы әллә? – дип төпченергә тотынды ул.

Миңнулла берара дәшми торды. Сәлимнән дә якынрак кешесе бармы икән аның? Аның алдында кычкырып елаган чакларын да хәтерли – күңеленә таш булып тулган хисләрне ерып җибәрергә дә оялып тормый, бөтен нәрсәне сөйләп, эчен бары тик аңа гына бушата ала. Сәлим көлмәс тә, гаеп тә итмәс, хәлгә керер, аңлар... Миңнулла үзе дә – Сәлим өчен шундый ук дус бит. Тик менә хәзер борчыган мәсьәләне сөйләп тору килешерме?! Ниһаять, ул бар ихтыяр көчен җыйды.

– Сәлим, ни эшләргә дә белгән юк бит әле монда, – диде ул, көрсенеп, һәм бармагы белән тагын берәрне салырга ишарәләде.

– Нәрсә тагын, балалар мәшәкате түгелдер бит?!

– Юк. – Икенче рюмка ашказанына төшеп урнашкач, Миңнулла ачылып киткәндәй булды. Үрелеп, итнең майлырак төшен сайлап капты, суганны кара икмәк өстенә куеп, мул итеп тешләп алды. – Мәшәкатем эшкә бәйле. Алай дип тә әйтеп булмый кебек инде. Кыскасы, болайрак. Эшләмичә өйдә утыра торган пенсионерлар пенсияне күбрәк ала икән...

– Минем кебекләр димәкче буласыңмы? – Сәлим чын күңелдән елмаеп куйды.

– Синең кебек дип... Кыскасы, әгәр мин эштән китсәм, минем пенсиям нәкъ җиде мең сумга артачак икән! Моны собеста эшләүче бер таныш кеше әйтте...

– Андый нәрсә бар дип мин дә ишеткән идем үзе... Соң, эштән китмәкче буласыңмыни?! Күптән вакыт, күптән. Бераз дөнья рәхәтен тоеп калырсың, бергәләп балыкка йөрербез...

– Балыкка йөрде ди... Беләсең бит, минем өчен балыкка йөрүнең кызыгы юк.

– Китапханәгә. Хәзер бездән ерак түгел китапханәгә ремонт ясадылар, керсәң, чыга торган түгел, шунда ук кәнәфигә утырып укырга да була, бөтен нәрсә өр-яңа, чип-чиста, шахматлары да бар, миңа уйнарга иптәш булыр иде ң ичмасам!

Миңнулла, юкны сөйләмә, дип, кулын селтәде һәм коньяк шешәсен якынрак тарта куйды.

– Пенсиягә байлар гына яши ала... Ай саен җиде мең сум югалтып барам бит мин, Сәлим!

– Аңлыйм, дустым, аңлыйм...

Миңнулла, дустына зур сер әйткәндәй, пышылдауга ук күчте:

– Аны болай итәләр икән. Пенсионерлар бер айга эштән китәләр, исәп-хисап алып, пенсиягә чыгарга гариза язалар. Бөтен документларны эшләп бетергәч, кире шул ук эшкә урнашалар. Дәүләт өчен ул пенсиядәге пенсионер дип санала. Ә үзе яңадан эшләп йөри...

– Берәрсе килеп тикшерсә? – Сәлим бу галәмәткә гаҗәпләнүен яшермәде.

– Тикшерде, ди, хәзер, тот капчыгыңны! Беркем дә алай кеше газаплап, олыларның рәнҗешен җыеп йөрергә теләми. Закон бозылмый.

– Тукта әле. Димәк, бу өстәмә түләүләргә Пенсия фондының да акчалары җитә булып чыга түгелме соң?

– Нәкъ шулай! Акчалары бар, беркем дә бөлгенлеккә төшми!

– Алайса, ник аны барысына да пенсия яшенә җиткәч белән генә түләмиләр соң?! Нигә кеше, интегеп, бер айга эштән китәргә, аннан соң кире алуларын ялварып килергә тиеш? Мантыйк кайда соң монда?!

– Мин каян белим?! Сәлим, син – укыган кеше бит, дөнья күргән кеше. Бездә мантыйк кайда булганы бар?!

– Башка сыймый ла бу! – Сәлимнең үзенең дә өянәге кузгалды бугай, ул, Миңнулла әйткәнне көтеп тормыйнитми, янә рюмкаларны тутырды. – Җиде мең сум! Ул бит... Ул бит... Шуны мескен пенсионерның авызыннан өзеп... Әллә инде ул түрәләр, мескен карт-корылар череп баеп китәр, дип куркамы?! Кирәк бит, ә?!

Миңнулла тынычлана калды – Сәлим бу юлы да дустының хәлен аңлады кебек. Аның гына түгел, шушы башка сыймаслык галәмәт аркасында төн йокысын югалткан миллионнарны да аңлады төсле. Коньягын бугазына койгач, рюмкасын шап итеп өстәлгә куйды да бик тәвәккәл кыяфәт белән Миңнуллага текәлде.

– Иртәгә үк! – диде ул, кулы белән кылычтай кизәнгән итеп. – Ишетсен колагың – иртәгә үк! Нәчәлнегеңә керәсең дә, бер айга увольнять итәсең, бер айдан кире эшкә аласың, дип әйтәсең! Бусы бер! Аннан соң марш собеска!

Миңнулла, дусты белән килешеп, башын каккан итте, әмма йөзендә әле бая гына кабынган көч, үз-үзенә ышаныч сүрелеп юкка чыккан иде инде.

– Шулаен шулай да... Анда ни бит әле... Әгәр бер айдан соң кире алмаса?!

Соңгы җөмләне Миңнулла шулай итеп әйтте ки, әйтерсең аның тамагына ябышып, ничәмә атналар буе сулыш алырга ирек бирмәгән төер чыгып китте. Шушы җөмләгә бөтен куркулары, айлар буе үткәрелгән йокысыз төннәре, йөрәгенә ятмаган ризыклары җыелган иде. Хәтта бөтен нәрсәне дә кичекмәстән эшләргә кирәклеген тормыш әләме итеп күтәреп яшәгән Сәлим дә бу сүзләрдән, аларны әйткәндә яңгыраган әрнүдән уйлана калды. Берара дәшми торгач, ул, инде саграк, тынычрак тавыш белән:

– Нәчәлнегең ниндирәк кеше соң? – дип сорады.

– Ниндирәк дип... Кем белгән инде аны?! Без сирәк күрешәбез. Әллә нигә бер кереп чыга. Яшь егет. Безнең эшне бар дип тә белмидер, мөгаен. Һава бозып утыралар, дип уйлыйдыр кебек...

– Шулай дип әйттемени?

– Әйтмәде. Кебек дидем бит...

– Әйтмәгәч, анысы яхшы. Өмет бар. Эшең буенча шелтәләр юктыр бит?!

Сорап торам тагын, юләр, сиңа да шелтә белдерсәләр... Миңнулла, менә нәрсә. Кереп сөйләш син аның белән. Төшеп калган кеше түгел бит син. Синең кебекне кайдан тапсын алар?! Яшьләр бик атлыгып тормыйдыр...

– Безнең урынга атлыгучы юк. Хезмәт хакы да әллә ни түгел, минем егерме биш меңнәр тирәсе чыга. Әле ике кызыбыз китеп барды, ике айдан бирле алар урынына кеше тебе алмыйлар...

– Әйтәм бит! Кер дә ирләрчә сөйләш! Гомер буе шунда эшләгән кешегә тел-теш тидерә алмас!

Сәлим, чираттагы рюмканы күтәреп, дустына текәлде. Ул кинәт Миңнулланың ни дәрәҗәдә үзгәргәнлеген күреп, имәнеп китте. Әллә ничек, капылт кына картайган төсле. Күзләре төпкә баткан, йөзендәге җыерчыклар арткан, тирәнәйгән...

– Яхшы чагында кер нәчәлнегеңә, юкса болай үзеңне генә бетерәсең!

Сәлим белән әле озак сөйләшеп утырдылар, яшьлек, балачакка кайтып килделәр, авылдашларны – исәннәрен «чәйнәп», мәрхүмнәрен искә алдылар. Бер шешә коньяк белән генә эш бетмәде, әлбәттә, Сәлим дә кайдандыр шешә тартып чыгарды.

Вакыт төнгә авышканда такси машинасына чыгып утырганда, Миңнулла, һичшиксез, иртәгә үк нәчәлнегe янын кереп, мәсьәләне кабыргасы белән куясына инанган иде. Мескенләнеп тору кая, таләп итәчәк! Ул гына башкалардан киммени?!

Күңеле йомшап китеп, ул хәтта карчыгына да җикеренмәде. Киресенчә, үзен бимазалаган шул өстәмә пенсия акчасы бәласен аңа да сөйләп бирде. Фәнүсә шунда ук Сәлим әйткәннәрне куәтләргә ашыкты. «Сиңа шунда да ярдәм итмәсәләр, җирбит булырлар, үзләре бәрәкәт күрә алмый интегерләр», – дип, иренә ышаныч өстәргә теләде. Айга өстәмә җиде мең сумның кесәне тишмәвен дә чамалап куярга өлгерде.

Икенче көнне Миңнулла чатнап авырткан башын чак кына күтәреп, эшкә китеп барды. Фәнүсә, аны озатканда, кичәге сөйләшүнә дәвам итәргә маташып, авызын ачкан гына иде, ире аны дорфа рәвештә бүлдереп ташлады...

Миңнулла ул көнне, әлбәттә, нәчәлнегe янына кереп, берни дә дауламады. Беркемгә дә күренмәскә тырышып, коллективы каршында үзен кичереп булмаслык гөнаһлы санап, кампитры артына яшеренеп, эшенә чумды. Икенче көн дә үтте, өченчесе дә – аяклары нәчәлнек ягына һич кенә дә атламады. Ул, бер яктан, үзен мескенлектә, икенче яктан шушы бернинди мантыйкка да сыймаслык мәсьәләне уйлап чыгарган түрәләрне имансызлыкта гаепләп, элеккечә интегеп йөри бирде...

Фәнүсә, әлбәттә, ирен хөрмәт итә торган хатын булса да, беренче чиратта ул барыбер хатын-кыз иде. Җиде мең турындагы мәгълүмат аның хәтеренә бик нык кереп сеңде. Һәм ул, хатын-кызларга гына хас осталык белән, иренең бәгыренә тамчылый башлады. Шул өстәмә җиде мең, кирәксә-кирәкмәсә, сөйләшүләргә, репликаларга, сүз арасындагы җөмләләргә әллә очраклы, әллә махсус рәвештә «ябыша» торган булды. Ахирәте белән телефоннан сөйләшкәндә: «Бакчада да мунча мичe эштән чыкты, бер җиде мең табылса, аны эшләтер идек тә бит», – дип бөтен өйгә ишетелерлек итеп кычкырып әйтүләр, тәрәзәдән карап торганда: «Кибеттән төянеп кайталар, бу букчаларындагы тауарлары гына да җиде меңгә тартадыр», – дип мыгырданулар һәм башка шундый шырпылар Миңнулланың болай да кан сауган йөрәгенә кадала торды.

Һәм ул тәвәккәлләде. Чөнки, чыннан да, бу мәсьәләгә нокта куярга кирәк иде. Пенсиягә җиде мең өстәмә акча аны көндез дә, төнлә, сирәк кенә йоклап киткән чакта кергән саташулы төшләрдә дә бимазалый. Миңнулла әлеге газаптан котыла алмый, шул газапның колына әверелде.

Тәвәккәлләгәч тә, озак әзерләнде. Дүшәмбе авыр көн, нәчәлнеккә дә җайлы түгел, иртә таңнан киңәшмәләрдә, төштән соң гына тәмам талчыгып килеп җитә. Сишәмбе, табигый, эш башламыйлар. Чәршәмбе инде кабул итү бүлмәсенә үк җиткән иде, бер бик мөһим таблицаны тутырмаганлыгын исенә төшереп, тиз генә кире үзләренең гомуми кабинетларына, кампитры каршына ашыкты. Пәнҗешәмбе көнне нәчәлнек эштә күренмәде. Миңнулла көне буе тәрәзәгә караштыргалап торды – машинасы тәки килмәде. Бу көнне ул очынып ук кайтты, ризыгы да тамагыннан үтте – нәчәлнегe янына керә алмауда үзе түгел, ә эшкә килмәгән җитәкчесе гаепле икәнлеген тою ничектер рәхәт иде. Җомга көнне исә тегесе иртәдән үк килде...

Ул, бар кыюлыгын җыеп, кабул итү бүлмәсенең бусагасыннан атлады. Биредә бик тыныч, әйтерсең, вакыт туктап калган. Тик чыныңда тормыш монда да үз җае белән агуын искәртеп, стенадагы сәгать кенә теркелди. Телефонына кадалып утырган кызый, ул тамагын кырып куйгач, аңа битараф карашын күтәрде.

– Исәнмесез, сез кем буласыз? – диде ул, кабат телефонына төртелеп.

– Миңнулла Садриев. Юридик затлар белән эшләү бүлегенең хисапчысы...

– Көтәме? – Сәркатип кыз, янә карашын күтәреп, нык имәннән эшләнгән көрән ишеккә ымлады.

– Юк, көтми. Мин шәхси мәсьәлә буенча...

Ахыры бар >

АТНА САЕН БЕР БҮЛӘК

ЯЗЫЛ!
2024 елның беренче яртыеллыгына
«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»
газетасына языл

П2435 >>
571 сум 98 тиен
(җомга)

П2409 >>
1255 сум 86 тиен
(сиш., чәрш., җомга)

КВИТАНЦИЯНЕ БЕЗГӘ ҖИБӘР!

89179270040

info@vatantat.ru

420097, Казан шәһәре,
Академия урамы, 2 нче йорт

БҮЛӘК ОТ!

Бу атна җиңүчесе – Саба районы Яңа Мичән авылыннан Тәвкил Ибраһимов. Котлыйбыз һәм элемтәгә чыгуыгызны үтенәбез.

ҖИҢҮЧЕ БУЛ!

Акциядә катнашучыларны гыйнвар аенда тагын да зуррак бүләкләр көтә

- ТУЗАН СУЫРТКЫЧ
- КЫСКА ДУЛКЫНЛЫ МИЧ
- ИТТАРТКЫЧ
- МУЛЬТИПЕКАРЬ
- ҮТҮК

Тулырак сайтта: vatantat.ru
Акция 2023 елның 29 сентябреннән башлап 2024 елның 10 февраленә кадәр дәвам итәчәк.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

Беләсең килсә...

1 Триатлонның беренче дисциплинасы нинди?
а) йөгерү;
б) йөзү;
в) велосипедта йөрү.

2 «Один дома 2» фильмында кемне күрергә була?
а) Дональд Трамп;
б) Джо Байден;
в) Барак Обама.

3 Натиформа нәрсә ул?
а) хатын-кыз формасына охшаган агач;
б) скульптурада тән әгъзасы сыны;
в) капка төбендә каршы алучы сыннар.

4 Евпатий Коловрат кайсы шәһәргә нигез салган?
а) Пенза;
б) Тверь;
в) Рязань.

Җаваплар: 1. б); 2. а); 3. а); 4. в).



Әз-мәз мәзәк

«Урыны белән» дигән сүз теләсә нинди һава торышы фаразын төгәл итә.

***

– Нишләп шундый күңелле әле син?
– Минем бүген туган көн.
– Синең атна саен туган көн.
– Әйе, чөнки сишәмбе туганмын.

***

Хатыныммың юбилеена быел 10 йомырка бүләк иттем.

***

– Матурым, син мине ишетәсеңме?
– Тагын бер әйт әле, vpn-ны сүндерергә оныткамын.

***

Ире эштән кайта һәм өстәлдә 20 шәм белән торт күрә:
– Тәк. Бүген кемнең туган көне әле?
– Матурым, бүген минем иске туныма –20 ел.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Атаказ, куак, ямб, кабартма, рәт, мим, буш, ата, ук, утар, кыяр, таяк, нам, Захар, мә, ни, до, сүс, без, гына, анар, фән, Нәбирә, атлану.

Вертикаль: Кораб, утын, ау, Урта, Идегәй, Такташ, Аяз, озын, ака, арка, ант, ана, акча, әл, аба, ятьмә, ян, Есенин, МММ, Урам, ару, бармак, Мәйсәрә.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ, ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ АППАРАТЫ

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2023 елның 23 августында теркәлгән. Теркәү таныклыгының номеры – ПИ № ТУ16-01758. Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 13596 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 369

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага өч тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+